# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

**№ 8**

**(II бүлек)**

**август**

**1999**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
1999

# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№8*
*август*
*1999*
*(II бүлек)*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
1999

Лицензия № 174 1996 елнық 03.10 бирелде
Җитештерүгә тапшырылды
Формат А5. Оригинал-макеттан басылды
Тиражы 1000 нөсхә. Заказы №2635
Бәясе килешү буенча.
"АБАК" нәшрияты.
420045 Казан, Н.Ершов ур., 31б.
Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять АБАК-хөзмәт күрсәтү үзәгендә басылды
Лицензия № 0080 1997 елның 03.12 бирелде
420107 Казан, Һади Такташ ур., 105

*ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696*
**Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы
© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 1999

# Эчтәлек

## I

660.«Вөҗдан ирege турында һәм дини берләшмәләр турында» *Татарстан Республикасы Законы* ........ 5

661.«Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында»*Татарстан Республикасы Законы* ........ 21

662.«Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре турында» *Татарстан Республикасы Законы* ........ 45

## II

663.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче пленар сессиясен чакыру турында»*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 63

664.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче пленар сессиясе каравына кертелүче мәсьәләләр турында»*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 63

## III

665.«Исәп-хисап ясауны җайга салу һәм хезмәт хакы түләүне тәэмин итү өчен финанс ресурсларын мобилизацияләү өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........ 63

666.«Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итү турында»*Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........ 63

667.«Тузган торак фондында яшәүче гражданнарга торак бирүнең кайбер үзенчәлекләре турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........ 67

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 660. Вөждан ирекге турында һәм дини берләшмәләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы,

Татарстан халыкларының рухиятен, мәдәниятен торгызуда һәм үстерүдә исламның һәм православиенең аерым ролен танып,

республика халыклары тарихи мирасының аерылгысыз өлешен тәшкил итүче башка диннәрне ихтирам итеп һәм аларның үзенчәлекләрен исәпкә алып,

дини экстремизм күренешләренең һәм дини берләшмәләр эшчәнлеге сәясиләшүенең куркынычлылыгын аңлап,

вөждан ирекге һәм дин тоту ирекге мәсьәләләрендә үзара аңлашуга, киң күңеллелек күрсәтүгә һәм ихтирамга ирешүгә ярдәм итүне мөһим дип санап,

әлеге Законны кабул итә.

#### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. **Төп төшенчәләр**

Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

вөждан ирекге - кешенең һәм гражданның дингә карата үз мөнәсәбәтен сайлап алу хокукы: дин тоту яисә гомумән дин тотмау хокукы;

дин тоту ирекге - кешенең һәм гражданның дини инануларында ирекле булу, шуларга бәйле ритуалларны, йолаларны үтәү, үз дине турында ачыктан-ачык игълан итү хокукы.

2 статья. Әлеге Законның җайга салу предметы

Әлеге Закон кеше һәм гражданның теләсә кайсы динне ирекле тоту яисә берсен дә тотмау, дини эшчәнлек белән шөгыльләнү буенча Татарстан Республикасы Конституциясендә беркетелгән хокукын тәэмин итү һәм гамәлгә ашыру гарантияләрен урнаштыра, дини берләшмәләрнең хокукый хәлен билгели.

3 статья. **Вөждан иреге, дин тоту иреге турындагы һәм дини берләшмәләр турындагы Татарстан Республикасы законнары**

Вөждан иреге, дин тоту иреге турындагы һәм дини берләшмәләр турындагы законнар Татарстан Республикасы Конституциясенең тиешле нормаларыннан, әлеге Законнан һәм башка төрле закон чыгару актларыннан гыйбарәт.

4 статья. **Вөждан иреге һәм дин тоту иреге хокукы**

1. Татарстан Республикасы гражданнары, инануларына карап, теләсә кайсы динне ирекле тотарга яисә берсен дә тотмаска, дини яисә атеистик эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокуклы. Дини йолаларны үтәүдә һәр кеше ирекле.

2. Дингә карата мөнәсәбәткә бәйле рәвештә өстенлекләр, чикләүләр яисә дискриминацияләүнең башка төрле рәвешләрен билгеләү рөхсәт ителми.

3. Кешенең һәм гражданның вөждан иреге һәм дин тоту иреге хокуклары закон нигезендә һәм суд карары буенча гына чикләнергә яисә туктатып торылырга мөмкин.

4. Татарстан Республикасы гражданнары, дингә мөнәсәбәтләренә һәм кайсы динне тотуларына карамастан, граждани, сәяси, икътисадый, социаль һәм мәдәни тормышның барлык өлкәләрендә дә закон каршында тигез булалар. Әгәр Татарстан Республикасы гражданының хәрби хезмәттә булуы аның инануларына яисә дин тотуына каршы килсә, ул законнарда билгеләнгән тәртиптә хәрби хезмәтне альтернатив вазыйфалар белән алмаштырырга хокуклы.

5. Беркем дә үзенең дингә мөнәсәбәтен башкаларга белгертергә тиеш түгел һәм беркем дә үзенең дингә, дин тотуга карата мөнәсәбәтен билгеләгәндә мәҗбүр ителмәскә яисә дин тотудан баш тартуга, гыйбадәт кылуларда, башка дини йолаларда һәм тантаналарда, дини берләшмәләр эшчәнлегендә һәм дин гыйлеме алуда катнашуга яисә катнашмауга мәҗбүр ителмәскә тиеш.

6. Вөждан иреге һәм дин тоту иреге хокукын гамәлгә ашыруга комачаулык итү, шул исәптән шәхескә карата көч куллану, дингә мөнәсәбәтләре аркасында гражданнарны күрәләтә мәсхәрәләү, дини өстенлекне пропагандалау, дини инанулар аркасында дошманлык, нәфрәт һәм милли каршылык уяту рәвешендә дә комачаулык күрсәтү йә мөлкәтне юк итү яисә аңа зыян салу белән, йә шундый гамәлләр кылу белән янау закон нигезендә тыела һәм эзәрлекләнә.

7. Дини ихтирам объектлары тирәсендә гавами гамәлләр үткәрү, уен-көлке биналары ачу, дин тотучы гражданнарның дини

хисләрен мәсхәрәләүче текстлар, сурәтләр һәм реклама урнаштыру тыела.

8. Бала дини инанулар буенча дискриминацияләүнең теләсә кайсы рәвешеннән саклап калына. Аңа карата дини ирексезләү, шул исәптән дини берләшмәгә җәлеп итү, шулай ук, үз теләге булмаса һәм, ата-аналарының яисә аларны алыштыручы затларның язма ризалыгыннан башка, аны дингә өйрәтү тыела.

9. Татарстан Республикасы территориясендәге чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз затлар вөҗдан ирекге һәм дин тоту ирекге хокукыннан Татарстан Республикасы гражданнары белән бертигез файдаланалар һәм вөҗдан ирекге турындагы, дин тоту ирекге һәм дини берләшмәләр турындагы законнарны бозган өчен законда билгеләнгәнчә җаваплы булалар.

10. Исповедь яшеренлеге закон белән саклана.

5 статья. **Дәүләт һәм дини берләшмәләр**

1. Татарстан Республикасында диннәр һәм дини берләшмәләр дәүләттән аерылганнар һәм закон каршында бертигез булалар.

2. Татарстан Республикасы территориясендә яңа дини тәгълиматларны тарату һәм беренче тапкыр төзелгән дини берләшмәләрнең эшчәнлеге җәмәгать татулыгы һәм җәмәгать иминлеге мәнфәгатьләрендә закон нигезендә чикләнергә мөмкин.

3. Дин һәм дини берләшмәләрнең дәүләттән аерылганлыгы турында конституциячел принцип нигезендә дәүләт:

гражданин үзенең дингә карата мөнәсәбәтен һәм кайсы дингә каравын билгеләгәндә, ата-аналар яисә аларны алыштыручы затлар үз инанулары һәм баланың вөҗдан ирекге, дин тоту ирекге хокукы нигезендә балаларны тәрбияләгәндә катышмый;

дәүләт хакимияте органнары, дәүләтнең башка органнары, дәүләт учреждениеләре һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаларын үтәүне дини берләшмәләргә йөкләми;

әгәр дини берләшмәләрнең эшчәнлеге законга каршы килмәсә, аңа катышмый;

дәүләткә караган һәм дәүләткә карамаган (дини булмаган) мәгариф учреждениеләрендә белем бирүнең дөньявилыгын тәэмин итә.

4. Дәүләт учреждениеләре һәм оешмалары бирүче һәм таләп итүче документларда гражданның дин тотуы күрсәтелми.

5. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, дәүләтнең башка органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә гавами дини йолалар һәм тантаналар катыштырылмый. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, дәүләтнең башка органнарының һәм җирле үзидарә органнарының урындагы затлары үзләренең хезмәт

урыннарын дингә карата теге яисә бу мөнәсәбәтне барлыкка китерү өчен файдаланырга хокуклы түгел.

6. Дәүләт дини оешмаларга тарихи һәм мәдәни ядкярләр булып саналган гыйбадәт биналарын һәм башка объектларны реставрацияләүдә, тотуда һәм саклауда финанс, матди һәм башка ярдәм күрсәтә, дини оешмаларга салым ташламалары һәм башка ташламалар бирүне җайга сала.

7. Дәүләт дини берләшмәләрнең хәйрия эшчәнлегенә, шулай ук аларның иҗтимагый әһәмияткә ия дини-агарту программаларын һәм чараларын гамәлгә ашыруларына ярдәм итә.

8. Диннең һәм дини берләшмәләрнең дәүләттән аерылганлыклары турында конституциячел принцип нигезендә дини берләшмә:

үз иерархия һәм институция структурасы нигезендә гамәлгә куела һәм эш итә, үз билгеләүләре нигезендә персоналын сайлый, билгеләп куя һәм алыштыра;

дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, дәүләтнең башка органнарының, дәүләт учреждениеләренең һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаларын үтәми һәм аларны алыштырмый;

дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына сайлауларда катнашмый;

сәяси хәрәкәтләр һәм фиркаләр эшчәнлегендә катнашмый, аларга матди һәм башка төрле ярдәм күрсәтми. 9. Дини берләшмәләрнең дәүләттән аерылулары әлеге берләшмәләр әгъзаларының хокукларын, дәүләт эшләренә идарә итүдә, дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына сайлауларда, сәяси фиркаләр, сәяси хәрәкәтләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегендә бүтән гражданнар белән бертигез катнашу хокукларын да кертеп, чикләүгә китерми.

10. Депутат итеп сайланган һәм дини берләшмәләр идарәләре органнарына керүче затларның шундагы эшчәнлеге аларның депутатлык вәкаләтләре чорына туктатып торыла.

11. Татарстан Республикасы территориясендә эшләп торучы дини берләшмәләр вөҗдан иреге, дин тоту иреге һәм дини берләшмәләр турындагы законнарны үтәргә тиеш.

12. Дини бәйрәмнәр Татарстан Республикасы законы нигезендә эш көннәре түгел дип игълан ителәләр.

6 статья. **Дин белеме**

1. Һәркем үзе теләгәнчә индивидуаль яисә башкалар белән бергә дин белеме алырга хокуклы.

2. Балаларны дини тәрбияләү һәм аларга дин белеме бирү ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның балаларын

үзләренең инанулары нигезендә тәрбияләү хокукына, баланың вөждан иреге һәм дин тоту иреге хокукына нигезләнә.

3. Дини тәрбия һәм дин белеме бирү һөнәри дин белеме учреждениеләрендә гамәлгә ашырылырга мөмкин. Дини берләшмәләр турыдан-туры дини берләшмәләрнең үзләрендә гражданнарга башлангыч дин белеме бирүне һәм дини тәрбияләүне гамәлгә ашырырга хокуклы.

4. Үзәкләштерелгән дини берләшмәләр үз уставлары нигезендә фәкать руханилар һәм дини персонал әзерләү өчен һөнәри дини белем учреждениеләре (рухани белем учреждениеләре) булдыру хокукына ия.

5. Һөнәри дин белеме учреждениеләре дини оешмалар буларак дәүләт теркәлүе үтәргә тиеш һәм белем бирү эшчәнлеген башкару өчен дәүләт лицензиясе алалар.

6. Дәүләт лицензиясе булган һөнәри дин белеме учреждениеләренең көндезге бүлекләрендә укучы гражданнар хәрби вазыйфа һәм хәрби хезмәт турындагы законнар нигезендә хәрби хезмәткә чакыруны кичектерү хокукыннан һәм законнарда каралган башка төрле өстенлекле ташламалардан файдаланалар.

7. Һөнәри дин белеме учреждениеләрендә дәүләт дини оешмалар үтенече буенча гомуми белем дисциплиналарын укытуга законнар нигезендә ярдәм күрсәтә.

8. Дини оешмалар үз уставлары нигезендә гомуми белем бирү учреждениеләре оештырырга хокуклы. Дәүләт әлеге учреждениеләргә белем бирү процессының уку-укыту һәм матди-техник тәэминатына законнар нигезендә ярдәм күрсәтә.

9. Дини йолалар үтәүгә бәйле булмаган һәм мәгълүмати характердагы дин гыйлеме, дини таныш белү, дини-фәлсәфи дисциплиналар укучыларның теләге буенча факультатив башлангычларда өйрәнелергә мөмкин.

### 7 статья. **Дин эшләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы**

Дин эшләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы мәгълүмати, консультатив, оештыру һәм эксперт учреждениесе була.

Дин эшләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы:
республикада дини вәзгыятьнең торышын анализлый һәм үсешен фаразлый;

дингә һәм дини берләшмәләргә карата дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча дәүләт идарәсе органнарының эшчәнлеген җайга сала;

вөждан иреге, дин тоту иреге турындагы һәм дини берләшмәләр турындагы законнарны куллануда дәүләт органнарына ярдәм итә;

дәүләти дин белеме экспертизасын оештыра һәм уздыра;

төрле диннәрнең дини берләшмәләре арасында үзара аңлашу һәм киң күңелллелек күрсәтүне ныгытуга һәм дини берләшмәләргә законнар нигезендә ярдәм күрсәтә;

Татарстан Республикасыннан читтәге шундый ук дәүләт органнары һәм дини берләшмәләр белән багланышларны һәм җайга салу элемтәләрен үстерә.

Җирле администрацияләр дини берләшмәләр белән эшләү буенча тиешле органнар төзергә хокуклы, мондый органнар исә үз функцияләрен әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка закон чыгару актлары нигезендә башкаралар.

## II бүлек. Дини берләшмәләр

8 статья. **Дини берләшмә**

1. Татарстан Республикасы гражданнарының, Татарстан Республикасы территориясендә даими һәм законлы нигезләрдә яшәүче башка затларның бергәләп дин тоту һәм дин тарату өчен төзелгән һәм түбәндәге максатка туры килә торган ирекле берләшүләре Татарстан Республикасында дини берләшмә дип танылa:

дин тотуга;

гыйбадәтләр кылуга, башка дини йолаларны һәм тантаналарны башкаруга.

2. Җәмгыятьтә турыдан-туры яисә массакүләм мәгълүмат чаралары аша дингә өйрәтү һәм дини тәрбия, үз инануларыңны тарату, шәфкатьлелек һәм хәйрия эшләре, дингә карата фидакарьлек эшчәнлеге һәм тиешле дини тәгълиматлар белән билгеләнүче башка эшчәнлек дин тотуга керә.

3. Дини берләшмәләр дини төркемнәр һәм дини оешмалар рәвешендә төзелергә мөмкин.

4. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарында һәм дәүләтнең башка органнарында, хәрби частьләрдә, дәүләтнең башка төрле оешмаларында, шулай ук җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларында дини берләшмәләр төзү тыела.

5. Максатлары һәм гамәлләре законга каршы килүче дини берләшмәләр төзү һәм аларның эшчәнлеге тыела.

9 статья. **Дини төркем**

1. Унсигез яшенә җиткән кимендә ун кешедән торган, бергәләшеп дин тоту һәм дин тарату максатларында төзелгән, гражданнарның дәүләт теркәве узмыйча гына һәм юридик затның хокукый сәләтенә ия булмыйча гына үз эшчәнлеген башкаручы ихтыярый берләшмәсе әлеге Законда дини төркем дип таныла. Дини

төркем биналары һәм аның эшчәнлеге өчен кирәкле мөлкәт төркем файдалануына анда катнашучылар тарафыннан бирелә.

2. Дини төркем төзегән гражданнар аның төзелүе һәм эшли башлавы турында җирле администрациягә һәм дин эшләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органына хәбәр итәләр. Хәбәрнамәгә дини тәгълиматның нигезләре һәм үзенчәлекләре турындагы, шуңа хас гамәлият турындагы белешмәләр кушымта итеп биреләләр.

3. Дини төркем гыйбадәт кылырга, башка дини йолаларны һәм тантаналарны башкарырга, шулай ук үзенең тарафдарларын дингә өйрәтергә һәм аларга дини тәрбия бирергә хокуклы.

4. Дини төркем, үзенең төзелүе хакында беренчел хәбәр иткәч кимендә унбиш елдан соң дини оешмага үзгәртелү юлы белән юридик зат статусы бирүне сорап, дини оешмаларны теркәүче Татарстан Республикасы юстиция органына мөрәҗәгать итәргә яисә үзәкләштерелгән дини оешмага керүен раслаучы документ тапшырырга мөмкин.

10 статья. **Дини оешма**

1. Татарстан Республикасы гражданнарының, Татарстан Республикасы территориясендә даими һәм законлы нигезләрдә яшәүче башка затларның бергәләп дин тоту һәм дин тарату максатларында төзелгән һәм законда билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак теркәлгән ихтыярый берләшүләре дини оешма дип таныла.

2. Территория билгесе буенча дини оешмалар җирле һәм үзәкләштерелгән оешмаларга бүленәләр.

3. Унсигез яшенә җиткән һәм бер урында йә берәр шәһәр яки авыл җирендә даими һәм законлы нигезләрдә яшәүче кимендә ун катнашучыдан торган дини оешма җирле дини оешма дип таныла.

4. Үз уставы нигезендә бер үк диндәге кимендә өч җирле дини оешмадан торган дини оешма үзәкләштерелгән дини оешма дип таныла.

5. Татарстан Республикасында мөселманнарның дини оешмалары бер үзәкләштерелгән дини оешмадан - Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтеннән гыйбарәт була һәм шуның тарафыннан идарә ителәләр.

Татарстан Республикасында Рус православие чиркәвенең дини оешмалары бер үзәкләштерелгән дини оешмадан - епархиядән гыйбарәт була һәм шуның тарафыннан идарә ителәләр.

6. Үз уставы нигезендә үзәкләштерелгән дини оешма тарафыннан төзелгән һәм әлеге Законның 8 статьясындагы 1 пунктында каралган максатка һәм билгеләргә ия булган учреждение яки

оешма, шул исәптән җитәкче йә җайга салучы орган яки учреждение, шулай ук һөнәри дин белеме учреждениесе дини оешма дип таныла.

7. Дини оешманың исемендә аның кайсы диннеке булуы хакында белешмәләр булырга тиеш. Дини оешма үз эшчәнлеген башкарганда тулы исемен күрсәтергә тиеш.

8. Дини оешма ел саен үзен теркәгән органга үз эшчәнлеген дәвам итүе хакында, юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелүче белешмәләрне күрсәтеп, мәгълүмат тапшырырга тиеш.

11 статья. **Дини оешмалар төзү**

1. Җирле администрация биргән документта кимендә унбиш ел дәвамында әлеге территориядә эшләп килүе турында раслануы яисә шул ук диндәге үзәкләштерелгән дини оешма структурасына керүе турында раслануы һәм күрсәтелгән оешма биргән раслануы булган дини төркемгә берләшкән Татарстан Республикасының кимендә ун гражданы җирле дини оешманың гамәлгә куючылары була алалар.

2. Үзәкләштерелгән дини оешмалар, әлеге Законның 10 статьясындагы 4 пункты нигезендә бер үк диндәге кимендә өч дини оешма булганда, закон һәм дини оешмаларның үз билгеләүләре нигезендә төзеләләр.

12 статья. **Дини оешманың уставы**

1. Дини оешма устав нигезендә эшли, устав исә дини оешманы гамәлгә куючылары яисә үзәкләштерелгән дини оешма тарафыннан раслана һәм граждан законнары таләпләренә туры килергә тиеш.

2. Дини оешма уставында түбәндәгеләр күрсәтелә:

дини оешманың исеме, урнашкан җире, төре, кайсы дингә каравы һәм, эшләп килүче үзәкләштерелгән дини оешмага карасa, аның да исеме;

эшчәнлекнең максатлары, бурычлары һәм төп рәвешләре;

эшчәнлекне төзү һәм аның эшчәнлеген туктату тәртибе;

оешманың структурасы, аның идарә органнары, аларны бар лыкка китерү тәртибе һәм оешманың компетенциясе;

оешманың акчаларын һәм башка мөлкәтен булдыру чыганаклары;

уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе;

эшчәнлеге туктатылган очракта, мөлкәт белән эш итү тәртибе;

әлеге дини оешманың эшчәнлеге үзенчәлекләренә кагылышлы башка белешмәләр.

13 статья. **Дини оешмаларны дәүләт теркәве**

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дини оешмаларны дәүләт теркәве Татарстан Республикасының юстиция органнары тарафыннан законда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Дин эшләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы кирәк чакта теркәүче органга теркәлүче дини оешманың тәгълимат нигезләре хакында дин белеме бәяләмәсе бирә.

2. Җирле дини оешмаларны дәүләт теркәве өчен гамәлгә куючылар Татарстан Республикасының юстиция органына түбәндәгеләрне тапшырырга тиеш:

теркәлү турында гариза;

дини оешманы төзүче затларның гражданлыгын, яшәү урынын, туган елын һәм көнен күрсәткән килеш, аларның исемлеге;

дини оешма уставы;

гамәлгә кую җыелышының беркетмәсе;

дини төркемнең әлеге территориядә кимендә унбиш ел дәвамында гамәлдә булуын раслаучы һәм җирле администрация тарафыннан бирелгән яисә дини төркемнең үзәкләштерелгән дини оешмага керүен раслаган документ, уставның нотариуста таныкланган күчермәсен һәм әлеге үзәкләштерелгән дини оешманы теркәү турындагы таныклыкны тапшырган килеш;

дин тәгълиматы нигезләре һәм аңа тиешле гамәлият, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә дин һәм әлеге дини берләшмә барлыкка килүнең һәм таралышының тарихы турында, аның эшчәнлек рәвешләре һәм алымнары, гаиләгә, никахка, белемгә карата мөнәсәбәтләре турында, әлеге дин тарафдарларының тотучыларның сәламәтлеккә карата мөнәсәбәтләре үзенчәлекләре хакында, оешма әгъзалары һәм руханилары өчен аларның граждани хокукларына һәм вазыйфаларына карата чикләүләр турындагы белешмәләр;

төзелүче дини оешманың урнашкан җирен (юридик адресын) раслаучы документ.

3. Әгәр төзелүче дини оешманың иң югары җитәкче органы (үзәге) чит дәүләт территориясендә урнашкан булса, әлеге статьяның 2 пунктында күрсәтелгән документларга өстәп, чит илдәге дини оешманың уставы яисә шушы оешманың үзе урнашкан дәүләтнең шуңа вәкаләтле органы раслаган башка нигези документ билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.

4. Үзәкләштерелгән дини оешмаларны, шулай ук үзәкләштерелгән дини оешмалар төзегән дини оешмаларны дәүләт теркәве өчен түбәндәгеләр нигез булып торалар:

теркәлү турында гариза;

дини оешманы гамәлгә куючылар исемлеге;

төзелүче дини оешманың гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) тарафыннан расланган уставы;

төзелүче дини оешманың җитәкче органы урнашкан җирен (юридик адресын) раслаучы документ;

уставның һәм гамәлгә куючының (гамәлгә куючыларның) дәү ләт теркәве узуы турындагы таныклыкның нотариуста расланган күчермәләре;

гамәлгә куючының (гамәлгә куючыларның) вәкаләтле органының тиешле карары.

5. Үзәкләштерелгән дини оешма төзелгәндә гамәлгә куючы (гамәлгә куючылар) үз структурасына керүче кимендә өч җирле дини оешманың уставын һәм шушы структурага керүче башка дини оешмалар турында белешмәләр тапшыралар.

6. Үзәкләштерелгән дини оешма яисә үзәкләштерелгән дини оешма биргән раслама нигезендә төзелүче дини оешманы дәүләт теркәвенә алу турындагы гариза әлеге статьяда каралган барлык документлар тапшырылган көннән соң бер ай эчендә карала.

7. Әлеге статьяның 3 пунктында каралган очракларда, шулай ук мондый дини тәгълиматның тарафдарлары булган мөрәҗәгать итүчеләр бу территориядә дини оешманы беренче тапкыр гына төзегән очракта, теркәүче орган дәүләт дини белеме экспертизасын үткәрү өчен документларны карауны алты айга кадәр озайтырга мөмкин. Әлеге экспертизаны үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

8. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүчеләр) әлеге статьяның 2-4 пунктларында каралган таләпләрне үтәмәгән очракта, теркәү органы, гаризаны, мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүчеләргә) бу хакта хәбәр итеп, карамаска да хокуклы.

9. Дини оешманы теркәү турындагы карар кабул ителгән очракта, теркәү органы мөрәҗәгать итүчегә дини оешманы дәүләт теркәвенә алу турында билгеләнгән үрнәктәге таныклык бирә һәм дәүләт теркәве турындагы белешмәләрне юридик затларның гомуми танышу өчен ачык булган бердәм дәүләт реестрына кертә.

10. Дини оешмаларның уставларына кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр дини оешмаларны теркәү өчен каралган тәртиптә дәүләт теркәве узарга тиеш, өченче затлар өчен дәүләт теркәве узган көннән алар үз көчләренә керәләр.

11. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелүче белешмәләр үзгәргән очракта, дини оешма мондый үзгәреш кертелгән көннән соң бер ай эчендә бу хакта теркәүче органга хәбәр итә.

12. Дини оешманы теркәгән өчен теркәү җыемы алына, аның суммасын Татарстан Республикасы Хөкүмәте билгели.

14 статья. **Дини оешманы дәүләт теркәвенә алудан баш тарту**

1. Дәүләт дини оешманы теркәүдән түбәндәге очракларда баш тартырга мөмкин:

дини оешманың максатлары һәм эшчәнлеге Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына-конкрет статьяларын күрсәтеп - каршы килсә;

төзелүче оешма дини буларак танылмаган булса;

устав һәм башка тәкъдим ителгән документлар законнар таләпләренә туры килмәсә яисә алардагы белешмәләр дөрес булмаса;

юридик затларның бердәм дәүләт реестрында мондый исемдәге оешма элегрәк теркәлгән булса;

гамәлгә куючы (гамәлгә куючылар) вәкаләтле булмаса.

2. Дәүләт дини оешмаларны теркәүдән баш тарткан очракта, кабул ителгән карар хакында мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүчеләргә), баш тартуның нигезләрен күрсәтеп, язма рәвештә хәбәр ителә.

3. Теркәү органының дини оешманы дәүләт теркәвеннән баш тартуына, шулай ук мондый теркәүдән читләшүгә карата судка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

15 статья. **Чит ил дини оешмаларының вәкиллекләре**

1. Чит дәүләт законнары нигезендә аның территориясендә төзелгән оешма чит ил дини оешмасы дип атала.

2. Чит ил дини оешмасына Татарстан Республикасы территориясендә үзенең вәкиллеген ачу хокукы бирелергә мөмкин.

3. Чит ил дини оешмасы вәкиллеге гыйбадәт кылу эшчәнлеге һәм башка төрле дини эшчәнлек белән шөгыльләнә алмый, аңа әлеге Закон белән билгеләнгән дини берләшмә статусы кагылмый.

4. Татарстан Республикасында чит ил дини оешмасы вәкиллекләрен теркәү, ачу һәм ябу тәртибе Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

5. Чит ил дини оешмасы вәкиллеген теркәү турындагы карар кабул ителгән очракта, аның вәкиленә мәгълүм үрнәктәге таныклык бирелә.

6. Билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасында теркәлгән үзәкләштерелгән дини оешмалар үзләрендә чит ил дини оешмалары вәкиллеге булдырырга хокуклы.

16 статья. **Дини оешма законнарны бозган очракта аны бетерү һәм аның эшчәнлеген тыю**

1. Дини оешмалар түбәндәгеләр буенча бетерелергә мөмкин:

гамәлгә куючылары яисә дини оешма уставы буенча шуңа вәкаләтле орган карары буенча;

Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм башка законнарның нормаларын берничә кат бозган яисә тупас бозган очракта йә дини оешманың төзелү максатларына (устав максатларына) каршы килүче эшчәнлекне даими башкарып торганда-суд карары буенча.

2. Дини оешманы суд тәртибендә бетерү, дини оешманың яисә дини төркемнең эшчәнлеген тыю өчен түбәндәгеләр нигез була:

җәмәгать иминлеген һәм җәмәгать тәртибен бозу, дәүләтнең иминлеген куркыныч астына кую;

Татарстан Республикасының конституциячел корылышы нигезләрен көч кулланып үзгәртүгә һәм Татарстан Республикасының бөтенлеген бозуга юнәлдерелгән гамәлләр;

хәрби формированиеләр төзү;

сугышны пропагандалау, социаль, расачыл, милли һәм дини каршылыклар китереп чыгару, кешеләргә карата нәфрәт уяту;

гаиләне таркатуга мәҗбүр итү;

шәхескә, гражданнарның хокукларына һәм ирегенә кизәнү;

гражданнарның дини эшчәнлекләренә бәйле рәвештә наркотик һәм психотроп чаралардан, гипноздан файдалануларын, бозык һәм хокукка каршы башка төрле гамәлләр кылуларны да кертеп, аларның әхлагына, сәламәтлегенә закон нигезендә билгеләнгән зыян китерү;

үз-үзенә кул салуга өндәү яисә гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янаган затларга дини мотивлар буенча медицина ярдәме күрсәтүдән баш тартуга өндәү;

гомуми һәм һөнәри белем алуга каршылык күрсәтү;

дини берләшмә әгъзаларын һәм тарафдарларын, башка затларны үз мөлкәтләреннән дини берләшмә файдасына баш тартырга мәҗбүр итү;

гражданның гомеренә, сәламәтлегенә, мөлкәтенә зыян салу белән янау рәвешендә (әгәр аны үтәүнең реаль куркынычы булса) яисә көч куллану рәвешендә, башка хокукка каршы гамәлләр рәвешендә аның дини берләшмәдән чыгуына каршылык күрсәтү;

гражданнарны закон белән билгеләнгән граждани вазыйфаларын үтәүдән баш тартуга яки башка төрле хокукка каршы гамәлләр кылуга этәрү;

үз исемен күрсәтмичә, башка дини оешмаларның исемен, символикасын куллану яисә, эшчәнлек алып бару.

3. Югарыда санап кителгән нигезләр аркасында бетерелгән дини оешмалар дәүләт теркәвен кабат узмыйлар.

4. Прокуратура органнары, дини оешмаларны теркәүче Татарстан Республикасы юстиция органы, дин эшләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы, шулай ук җирле администрацияләр дини оешманы бетерү йә дини оешманың яки дини төркемнең эшчәнлеген тыю хакында әлеге статьяның 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча судка тәкъдим кертергә хокуклы.

5. Бетерелә торган дини оешманың юридик зат буларак хокукый сәләте туктатыла, ә аның мөлкәте исә закон һәм үз уставы нигезендә бүленеп бирелә.

6. Суд карары буенча дини оешманы бетерү нигезләре һәм тәртибе дини төркем эшчәнлеген тыюга карата да кулланыла.

## III БҮЛЕК. ДИНИ ОЕШМАЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ ГАРАНТИЯЛӘРЕ

### 17 статья. Дини оешмаларның эчке күрсәтмәләре

1. Дини оешмаларның эчке күрсәтмәләре законнарга каршы килмәсәләр һәм алар уставларында каралган хокукый сәләткә ия булсалар, дини оешмалар шушы эчке күрсәтмәләре нигезендә эш итәләр.

2. Әгәр әлеге күрсәтмәләр законнарга каршы килмәсәләр, дәүләт дини оешмаларның эчке күрсәтмәләрен ихтирам итә.

### 18 статья. Дини оешмаларның милекчелек хокукы

1. Дини оешмаларның милкендә биналар, җир кишәрлекләре, җитештерү, социаль, хәйрия, дини-агарту һәм башка билгеләнештәге объектлар, дини билгеләнештәге предметлар, акчалар һәм дини оешмаларның эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле бүтән төрле мөлкәт була, шул исәптән тарихи һәм мәдәни ядкярләргә караганнары да.

2. Дини оешмалар үз акчаларына, гражданнарның, оешмаларның иганә акчаларына сатып алынган яисә төзелгән яки дәүләт тарафыннан дини оешмалар милкенә тапшырылган йә законнарга каршы килмәүче башка нигезләрдә сатып алынган мөлкәткә карата милекчелек хокукына ия булалар.

3. Дини оешмалар вакыф мөлкәтенә ия булырга хокуклы. 4. Дәүләт милкендәге гыйбадәт биналары һәм корылмалары,

үзләренә караган җир кишәрлекләре белән бергә, һәм дини билгеләнештәге башка төрле мөлкәт дини оешмалар милкенә түләүсез тапшырыла.

5. Дини оешмалар чит илләрдәге мөлкәткә милекчелек хокукында ия булырга мөмкин.

6. Гыйбадәт кылу билгеләнешендәге күчемле һәм күчемсез мөлкәткә карата кредиторлар дәгъвасы буенча түләү алынмаска

тиеш. Кредиторлар дәгъвасы буенча түләү алынмый торган гыйбадәт кылу билгеләнешендәге күчемле һәм күчемсез мөлкәт төрләре исемлеген дини оешмаларның тәкъдимнәре буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте билгели.

19 статья. **Дини йолалар һәм тантаналар**

1. Дини оешмалар гыйбадәт биналары һәм корылмалары, гыйбадәт кылу, дога кылу һәм дини җыелышлар үткәрү өчен махсус урыннарга һәм объектларга, дини ихтирам урыннарына һәм объектларына нигез салырга һәм аларны тотарга хокуклы.

2. Гыйбадәт кылулар, башка дини йолалар һәм тантаналар гыйбадәт биналарында, корылмаларында һәм аларга караган территорияләрдә, дини ихтирам урыннарында, дини оешмаларның учреждениеләрендә һәм предприятиеләрендә, зиратларда һәм крематорийларда, шулай ук торак урыннарында тоткарлыксыз башкарыла. Мәдәният учреждениеләрендә, спорт корылмаларында, башка җәмәгать урыннарында дини йолалар һәм тантаналар җирле администрацияләр, җирле үзидарә органнары һәм дин эшләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы ризалыгы белән үткәрелә.

3. Хәрби частьләрнең командованиесе, хәрби уставларның таләпләрен исәпкә алып, хәрби хезмәткәрләрнең гыйбадәт кылуларда, башка дини йолаларны һәм тантаналарны үтәүдә катнашуларына закон нигезендә каршылык күрсәтми.

4. Дини оешмалар медицина учреждениеләрендә, балалар йортларында, картлар һәм инвалидлар өчен интернат йортларда, иректән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзасын үтәүче учреждениеләрдә андагы гражданнарның үтенече буенча һәм бу максатлар өчен администрация тарафыннан махсус бирелгән биналарда дини йолалар башкарырга хокуклы. Сак астында тоту урыннарындагы биналарда дини йолалар үткәрү законнарның таләпләрен үтәгән килеш рөхсәт ителә.

5. Башка төрле очракларда гавами гыйбадәт кылулар, башка дини йолалар һәм тантаналар Татарстан Республикасы территориясендә массакүләм гамәлләр үткәрү өчен билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

6. Дин тотучылар үтенече буенча предприятиеләрнең хезмәт көне тәртибендә Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә дини йолаларны үтәү өчен хезмәткәрләргә тәнәфес бирелергә мөмкин. Тәнәфес эш вакытына кертелми.

20 статья. **Халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә дини гореф-гадәтләр**

Дини оешмалар сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләренең махсуслаштырылган челтәрен төзергә, дин тоту-

чыларга канон таләпләре нигезендә хезмәт күрсәтү өчен яңа медицина учреждениеләре ачарга мөмкин.

**21 статья. Дини әдәбият һәм дини билгеләнеш предметлары**

1. Дини оешмалар дини әдәбиятны, басма, аудио- һәм видеоматериалларны, дини билгеләнештәге башка төрле предметларны җитештерергә, сатып алырга, читтән кертергә, читкә чыгарырга һәм таратырга хокуклы.

2. Дини оешмалар гыйбадәти әдәбият бастырып чыгаручы һәм гыйбадәт кылу предметларын җитештерүче оешмаларны гамәлгә кую, шулай ук гыйбадәт кылу биналарыннан тыш аларны гамәлгә ашыру буенча аерым хокуктан файдаланалар.

3. Дини оешмалар чыгара торган әдәбият, басма, аудио- һәм видеоматериаллар әлеге дини оешманың тулы рәсми исеме белән тамгаланырга тиеш.

**22 статья. Дини оешмаларның хәйрия һәм агарту эшчәнлеге**

1. Дини оешмалар хәйрия эшчәнлеген турыдан-туры да, хәйрия оешмаларын гамәлгә кую юлы белән дә закон нигезендә тормышка ашырырга хокуклы.

2. Дини оешмалар үзләренең устав максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә дини-агарту, белем бирү һәм башка төрле учреждениеләр төзергә, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә куярга хокуклы.

**23 статья. Халыкара багланышлар һәм элемтәләр**

1. Дини оешмалар халыкара багланышлар һәм элемтәләр урнаштырырга һәм тотарга хокуклы, шул исәптән дини ихтирам урыннарына бару, җыелышларда һәм башка гамәлләрдә катнашу өчен, дини белем алу өчен дә, шулай ук шушы ук максатлар өчен чит ил гражданнарын да чакырырга хокуклы.

2. Дини оешмалар, дин эшләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы белән килешеп, әлеге оешмаларда һөнәри, шул исәптән вәгази, мөгаллимлек эшчәнлеге белән шөгыльләнү максатларында чит ил гражданнарын чакыру өчен законнар нигезендә аерым хокукка ия.

**24 статья. Дәүләт милке, гражданнар һәм аларның берләшмәләре милке булган мөлкәттән файдалану**

1. Дини оешмалар әлеге Законда билгеләнгән максатлар өчен дәүләт (республика һәм коммуналь) берләшмәләре, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар биргән һәм гражданнар тара-

фыннан бирелгән җир кишәрлекләреннән, биналардан һәм башка төрле мөлкәттән файдаланырга хокуклы.

2. Дини оешмаларга вазыйфаи билгеләнештә файдалану өчен дәүләт милкендәге һәм җирле үзидарә милкендәге гыйбадәт биналарын һәм корылмаларын, аларга караган җир кишәрлекләре белән бергә, дини билгеләнештәге башка төрле мөлкәт түләүсез тапшырыла.

25 статья. **Дини оешмаларның акчалары**

Дини оешмаларның акчалары физик һәм юридик затларның ирекле иганәләре, гыйбадәт эшчәнлегеннән, гыйбадәт кылу һәм дини билгеләнеш предметларын, дини әдәбиятны җитештерүдән һәм сатудан кергән акчалар исәбенә, шулай ук законнарда тыелмаган башка акча керту чыганакларыннан барлыкка килә.

26 статья. **Дини оешмаларның эшкуарлык эшчәнлеге**

Дини оешмалар законнарда билгеләнгән тәртиптә эшкуарлык эшчәнлеген башкарырга һәм үз предприятиеләрен төзергә хокуклы.

27 статья. **Дини оешмаларда хезмәт хокукы мөнәсәбәтләре**

1. Дини оешмалар үз уставлары нигезендә хезмәткәрләр белән хезмәт шартнамәләре (контрактлар) төзергә хокуклы.

2. Хезмәт шартлары һәм хезмәт өчен түләү дини оешма (эш бирүче) белән хезмәткәр арасында төзелә торган хезмәт шартнамәсе (контракт) буенча закон нигезендә билгеләнә.

3. Дини оешмаларда хезмәт шартнамәләре (контрактлары) буенча эшләүче гражданнарга хезмәт турындагы законнар кагыла.

4. Дини оешмаларның хезмәткәрләре, шулай ук дин әһелләре законнар нигезендә социаль тәэмин ителергә, социаль иминләштерелергә һәм пенсия белән тәэмин ителергә тиеш.

## IV БҮЛЕК. ВӨҖДАН ИРЕГЕ, ДИН ТОТУ ИРЕГЕ ТУРЫНДАГЫ ҺӘМ ДИНИ БЕРЛӘШМӘЛӘР ТУРЫНДАГЫ ЗАКОННАР ҮТӘЛЕШЕНӘ КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ КОНТРОЛЬЛЕК ИТҮ

28 статья. **Дини эшчәнлек өлкәсендә күзәтчелекне һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыру**

1. Вөҗдан иреге, дин тоту иреге турындагы һәм дини берләшмәләр турындагы законнар үтәлешенә күзәтчелекне Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары гамәлгә ашыра.

2. Дини оешмаларның эшчәнлекләре максатларына һәм асылына карата уставларын тикшереп торуны дини оешмаларны теркәүче орган һәм дин эшләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы башкара.

29 статья. **Вөждан иреге, дин тоту иреге турындагы һәм дини берләшмәләр турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык**

Вөждан иреге, дин тоту иреге турындагы һәм дини берләшмәләр турындагы Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен законнар нигезендә җаваплылык карала.

30 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Дини оешмаларның әлеге Закон үз көченә кергәнче төзелгән уставлары һәм башка төрле гамәлгә куюю документлары әлеге Законга яраклаштырылырга тиеш. Дини оешмаларның уставларын һәм башка төрле гамәлгә куюю документларын әлеге Законга яраклаштырганчы, алар әлеге Законга каршы килмәгән өлешләрендә генә гамәлдә булалар.

2. Татарстан Республикасы Хөкүмәте өч ай эчендә үзенең норматив-хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга тиеш.

3. Әлеге Закон үз көченә кергәнче төзелгән дини оешмаларны дәүләт теркәвенә алу әлеге Закон таләпләре нигезендә 2000 елның 1 июленнән дә соңга калмыйча үткәрелергә тиеш. Бу вакыт узганнан соң кабат теркәлү узмаган дини оешмалар суд тәртибендә бетерелергә мөмкин.

4. Дини оешмаларны бетерү яисә аларның эшчәнлеген тыю өчен әлеге Законның 16 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булса, дини оешмаларны кабат теркәү уздырылмый. Әлеге нигезләр буенча кабат теркәүдән баш тарткан теркәүче орган материалларны судка тапшыра.

5. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2279

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 661. Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында

Әлеге Закон әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә хокук бозулар өчен гражданнарның,

урындагы затларның, индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның административ җаваплылыгын билгели.

## I БҮЛЕК. ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ МОХИТНЕ САКЛАУ ҺӘМ ТАБИГАТЬТӘН ФАЙДАЛАНУ ӨЛКӘСЕНДӘ АДМИНИСТРАТИВ ХОКУК БОЗУЛАР

### 1 статья. **Җир асты байлыкларын саклау таләпләрен бозу**

Файдалы казылмалар яткан мәйданнарда үз белдеге белән төзелеш эшләре алып барган өчен, җир асты байлыкларын саклау кагыйдәләрен һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрнең зарарлы йогынтысыннан әйләнә-тирә табигать мохитен саклау таләпләрен үтәмәгән өчен, җир асты суларын режимлы күзәтеп тору скважиналарын, шулай ук маркшейдер һәм геодезик тамгаларны юкка чыгарган яисә аларга зыян китергән өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

Файдалы казылмаларга бай ятмаларның кишәрлекләрен сайлап алып, шундагы файдалы казылмаларның баланс запасларын нигезсез югалтуларга китерерлек итеп эшкәрткән өчен, файдалы казылмаларны чыгарганда аларны нормативтан тыш югалткан һәм нормативтан тыш ярлыландырган өчен, файдалы казылмаларның ятмаларына зыян китергән өчен һәм аларның запасларыннан нәтиҗәле файдалану таләпләрен башкача бозган өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

Маркшейдер документларын югалткан өчен, бетерелүче яисә консервацияләнүче тау эшләнмәләрен һәм бораулау скважиналарын халыкның иминлеген тәэмин итәрлек халәткә китерү таләпләрен, шулай ук ятмаларны,тау эшләнмәләрен һәм консервацияләү вакытында бораулау скважиналарын саклау таләпләрен үтәмәгән өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

### 2 статья. **Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару кагыйдәләрен һәм таләпләрен бозу**

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару

кагыйдәләрен һәм таләпләрен файдалы казылмаларның разведкаланган запасларын дөрес булмаганча бәяләргә мөмкин булырлык итеп яисә шуңа китерерлек итеп бозган өчен яки файдалы казылмалар чыгаручы предприятиеләрне, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм аларны эксплуатацияләү шартларын бозган өчен, җир асты байлыкларын киләчәктә өйрәнгәндә һәм ятмаларны эшкәрткәндә кирәк булырлык геологик документларны, файдалы казылмаларның һәм кернның проба дубликатларын югалткан өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

3 статья. **Су объектларын саклау кагыйдәләрен бозу**

Су объектларын пычраткан һәм чүпләндергән өчен, аларның су җыю мәйданнарында су саклау режимын су объектларының пычрануын, туфракны су белән эрозияләүне һәм башка зарарлы күренешләрне китереп чыгарырлык итеп бозган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

Хуҗалык объектларын суларны пычратмый һәм чүпләндерми торган корылмаларсыз һәм җайланмаларсыз эксплуатацияләүгә тапшырган өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

4 статья. **Су объектларын бетәштерү яисә юкка чыгару**

Су ресурсларын нәтиҗәсез файдаланган яисә су объектларына аларның бетәшүенә яки юкка чыгуына китерерлек итеп башка төрле зарарлы йогынты ясаган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

5 статья. **Су хуҗалыгы һәм су саклау корылмаларын, җайланмаларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозу**

Су хуҗалыгы һәм су саклау корылмаларын, җайланмаларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозган өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә юридик затларга хезмәт өчен түләүнең ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**6 статья. Агачларны һәм куаклыкларны законсыз кисү яисә зарарлау**

Торак пунктлары чикләрендә урнашкан агачларны һәм куаклыкларны үсеп китә алмаслык дәрәҗәдә законсыз кискән яисә зарарлаган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

**7 статья. Үсемлекләр дөньясын карантинга китерүче корткычлардан, үсемлек авыруларыннан һәм чүп үләннәрдән саклау кагыйдәләрен бозу**

Үсемлекләр дөньясын карантинга китерүче корткычлардан, үсемлек авыруларыннан һәм чүп үләннәрдән саклау кагыйдәләрен бозган өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

**8 статья. Татарстан Республикасы территориясенә карантин тикшерүен һәм тиешле эшкәртү узмаган материалларны кертү**

Татарстан Республикасы территориясенә карантин тикшерүен һәм тиешле эшкәртү узмаган материалларны керткән өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**9 статья. Кызыл китапка кертелгән үсемлекләрне законсыз җыю, юкка чыгару, зарарлау, сатып алу, сату, бер урыннан икенче урынга күчерү һәм Татарстан Республикасыннан читкә чыгару**

Россия Федерациясенең Кызыл китабына яисә Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән төрләргә караучы

үсемлекләрне, аларның продуктларын, өлешләрен һәм дериватларын законсыз җыйган, юкка чыгарган, зарарлаган, сатып алган, саткан, бер урыннан икенче урынга күчергән һәм Татарстан Республикасыннан читкә чыгарган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

10 статья. **Төп файдаланудагы урманнарны кисү, арадаш файдаланудагы урманнарны кисү һәм урманнарны башкача кисү кагыйдәләрен бозу**

Төп файдаланудагы урманнарны кисү, арадаш файдаланудагы урманнарны кисү һәм урманнарны башкача кисү кагыйдәләрен, шулай ук урманнарны кисү процессларына карата технологик таләпләрне бозган өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

11 статья. **Нектарлы агач-куакларны кисү кагыйдәләрен бозу**

Стационар умарталыклар урнашкан урыннардан һәм умарта күчләре булган торак пунктларыннан 3 километр радиуска кадәр, урманнарның санитар торышын һәм аларны кабат торгызу шартларын яхшырту очракларыннан тыш, нектарлы агач-куакларны кисү кагыйдәләрен, шулай ук тал кайрысы әзерләү кагыйдәләрен бозган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ике минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

12 статья. **Икенчел урман материалларын әзерләү кагыйдәләрен бозу**

Икенчел урман материалларын (агач төпләрен, юкә кабыгын, кайры, каен тузын әзерләү, ак чыршы, нарат һәм чыршы ботакларын) әзерләү кагыйдәләрен бозган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

**13 статья. Урманнардан өстәмә файдалану кагыйдәләрен бозу**

Урман фонды җирләрендә яисә тыелган кишәрлекләрдә печән чапкан һәм көтү көткән өчен, шулай ук тирәсе тотылмаган көтүлекләрдә терлекләрне күзәтүчесез яисә бәйләп куймыйча йөрткән өчен, терлекләрне көтү вакытларын һәм нормаларын бозган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

Умарталар һәм умарталыклар урнаштыру, агач сутларын әзерләү, кыргый җимешләр, чикләвекләр, гөмбәләр, җиләкләр, дару үләннәре һәм ашарга яраклы үсемлекләр яисә аларның өлешләрен, техник чималны җыю яки кәсби әзерләү тыелган яисә бары тик урман билеты буенча гына рөхсәт ителгән кишәрлекләрдә шушыларны башкарган өчен, шулай ук әзерләүләре тыелган үсемлекләрне әзерләгән өчен, аларны рөхсәт ителмәгән ысуллар һәм җайланмалар белән яки билгеләнгән күләмнәрдән артыграк әзерләгән өчен, җыюның яисә кәсби әзерләүнең билгеләнгән вакытларын бозган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең бер минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең утыз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**14 статья. Урман фондыннан урман кисү билетында (ордерында) яисә урман билетында каралган максатларга яисә таләпләргә туры китермичә файдалану**

Урман фондыннан урман кисү билетында (ордерында) яисә урман билетында каралган максатларга яки таләпләргә туры китермичә файдаланган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең унбиш минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең җитмеш биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

**15 статья. Урман кисү, икенчел урман материалларын әзерләү урыннарын таныклау тәртибен бозу**

Урман кисү, икенчел урман материалларын әзерләү урыннарын таныклау тәртибен бозган өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

**16 статья. Урман хуҗалыгын алып бару кагыйдәләрен бозу**

Урман фонды хуҗасы урман хуҗалыгын алып бару кагыйдәләрен бозган өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**17 статья. Агачларны, куаклыкларны законсыз кисү, казып алу яисә зарарлау, урман культураларын, плантацияләрне, урман питомникларындагы ясалма, шулай ук табигый чәчкеннәрне йә үсентеләрне юкка чыгару яисә зарарлау**

Агачларны, куаклыкларны законсыз кискән, казып алган яисә зарарлаган, урман культураларын, плантацияләрне, урман питомникларындагы ясалма, шулай ук табигый чәчкеннәрне йә үсентеләрне юкка чыгарган яисә зарарлаган өчен, аларны башбаштакланып казып алган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**18 статья. Урман түшәлмәсен яисә мүген, сазлык япмасын башбаштакланып җыю, аларга зыян китерү яисә аларны юкка чыгару, урман туфрагының уңдырышлы катламына зыян китерү яки аны юкка чыгару**

Урман түшәлмәсен яисә мүген, сазлык япмасын башбаштакланып җыйган, аларга зыян китергән яисә аларны юкка чыгарган өчен, урман туфрагының уңдырышлы катламына зыян китергән яки аны юкка чыгарган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

**19 статья. Урман фаунасын юкка чыгару**

Кырмыска ояларын, кош-корт ояларын, җәнлек өннәрен һәм хайваннар тереклек итүче башка урыннарны юкка чыгарган

(туздырган), йомырка салынган ояларны юкка чыгарган яисә йомыркаларны җыйган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

20 статья. **Урман фонды җирләрендәге печәнлекләрне һәм көтүлекләрне, урманнарны киптерү канауларын, дренаж системаларын юкка чыгару яисә зарарлау**

Урман фонды җирләрендәге печәнлекләрне һәм көтүлекләрне, урманнарны киптерү канауларын, дренаж системаларын юкка чыгарган яисә зарарлаган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

21 статья. **Урманнарда санитар кагыйдәләрне бозу**

Урманнарда санитар кагыйдәләрне бозган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

22 статья. **Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозу**

Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган өчен

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

23 статья. **Чикләү тамгаларын, урман корылышы тамгаларын, кече архитектура формаларын, күрсәткечләрне, янгынга каршы аншлагларны юкка чыгару яисә зарарлау**

Чикләү тамгаларын, урман корылышы тамгаларын, кече архитектура формаларын, күрсәткечләрне, янгынга каршы аншлагларны юкка чыгарган яисә зарарлаган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ике минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

**24 статья. Минераль ашламаларны һәм үсемлекләрне яклауның химик чараларын саклау һәм куллану кагыйдәләрен бозу**

Минераль ашламаларны һәм үсемлекләрне яклауның химик чараларын саклау һәм куллану кагыйдәләрен бозган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**25 статья. Халыкка алдан хәбәр итмичә пестицидлар куллану**

Халыкка алдан хәбәр итмичә пестицидлар кулланган өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең өчтән алып унбиш минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең уннан алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

**26 статья. Махсус саклanылучы табигать территорияләренең һәм башка табигать объектларының билгеләнгән режимын бозу**

Дәүләт табигать тыюлыклары, дәүләт табигать заказниклары, милли табигать парклары, табигать ядкярләре территорияләрендә һәм махсус сакланылучы башка төрле табигать территорияләрендә, аларның саклanучан зоналарында, шулай ук курорт, дәвалау-сәламәтләндерү, мохитне саклау, санитария-гигиена һәм рекреация функцияләрен үтәүче бүтән табигать территорияләрендә билгеләнгән режимны яисә әйләнә-тирә табигать мохитен һәм табигый байлыкларны саклауның башка төрле кагыйдәләрен бозган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең кырык минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**27 статья. Транспорт чараларын шушы максатлар өчен билгеләнмәгән урыннарда юу**

Транспорт чараларын шушы максатлар өчен билгеләнмәгән урыннарда юган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

Урманнарда һәм су объектларының су саклау зоналарында транспорт чараларын юган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

**28 статья. Хайваннарның тереклек итү тирәлегең һәм миграция юлларын саклау кагыйдәләрен бозу**

Хайваннарның тереклек итү тирәлеген яисә миграция юлларын саклау кагыйдәләрен бозган өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

**29 статья. Зоологик коллекцияләрне төзүнең һәм куллануның билгеләнгән тәртибен бозу, шулай ук хайваннарны башбаштакланып башка урынга күчерү, климатлаштыру һәм кушылдыру**

Зоологик коллекцияләрне төзүнең һәм куллануның билгеләнгән тәртибен бозган, шулай ук хайваннарны башбаштакланып башка урынга күчергән, климатлаштырган һәм кушылдырган өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**30 статья. Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясыннан файдалану кагыйдәләрен һәм нормаларын бозу, шулай ук Кызыл китапка кертелгән хайван төрләренең сакланып калуына зыян китерерлек дип танылган хайваннарны һәм үсемлекләрне читтән законсыз кертү**

Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясыннан файдалануны гамәлгә ашыруның билгеләнгән тәртибен бозган, шулай ук Кызыл китапка кертелгән хайван төрләренең сакланып калуына зыян китерерлек дип танылган хайваннарны һәм үсемлекләрне Татарстан Республикасына законсыз керткән өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**31 статья. Сирәк очрый торган һәм бетү куркынычы булган хайваннарны юк итү**

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайван төрләренә караучы сирәк очрый торган һәм бетү куркынычы булган хайваннарны юк иткән яисә алар салган йомыркаларны, аларның торакларын һәм башка корылмаларын юк иткән яки мондый хайваннарның һәлак булуына, аларның санын киметүгә яисә тереклек итү тирәлеген бозуга китерүче башка гамәлләр кылган йә андый хайваннарны кулга төшерү өчен бирелгән рөхсәттә күрсәтелгән шартларны бозып аларны кулга төшергән өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

**32 статья. Хайваннар дөньясыннан файдалану кагыйдәләрен бозу**

Хайваннар дөньясыннан файдалану кагыйдәләрен бозган өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең бер минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

**33 статья. Су җыйгычларны балыкларны саклау корылмалары булмаган килеш эксплуатацияләү**

Су җыйгычларны балыкларны саклау корылмалары булмаган килеш эксплуатацияләгән өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**34 статья. Хайваннар дөньясы объектларын кулга төшерү, әзерләү, сату, сатып алу, алыштыру, бер урыннан икенче урынга җибәрү, читтән кертү һәм читкә чыгару кагыйдәләрен бозу**

Хайваннар дөньясы объектларын, аларның продуктларын, өлешләрен һәм дериватларын, шулай ук зоологик коллекцияләрне кулга төшерү, әзерләү, сату, сатып алу, алыштыру, бер урыннан икенче урынга җибәрү, читтән кертү һәм Татарстан Республикасыннан читкә чыгару кагыйдәләрен бозган өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен

түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

35 статья. **Балыклар уылдык чәчкән урыннарда, двигатель файдаланып, аз сыйдырышлы судноларда балыклар уылдык чәчкән вакытта рөхсәтсез генә йөзү**

Балыклар уылдык чәчкән урыннарда, двигатель файдаланып, аз сыйдырышлы судноларда махсус вәкаләтле дәүләт органнары рөхсәтеннән башка балыклар уылдык чәчкән вакытта йөзгән өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

36 статья. **Бал кортлары күчләре биләгән куышлары булган агачларны ярамаганын белә торып кисү**

Бал кортлары күчләре биләгән куышлары булган һәм урман хуҗалыклары исәбендә торучы агачларны урман хуҗалыгы эшләрен башкарганда ярамаганын белә торып кискән өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

37 статья. **Кыргый бал кортларыннан бал алу кагыйдәләрен бозу**

Урманнарда тереклек итүче бал кортларының ояларыннан аларга торакларында тиешле азык запаслары калдырмыйча бал алган өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

38 статья. **Милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрне, корылмаларны, технологик линияләрне, җайланмаларны һәм башка төрле объектларны планлаштырганда, техник-икътисадый нигезләгәндә, проектлаштырганда экологик таләпләрне бозу**

Милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрне, корылмаларны, технологик линияләрне, җайланмаларны һәм башка төрле

объектларны планлаштырганда, техник-икътисадый нигезләгәндә, проектлаштырганда экологик таләпләрне бозган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

39 статья. **Милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрне, корылмаларны, технологик линияләрне, җайланмаларны һәм башка төрле объектларны урнаштырганда, төзегәндә, реконструкцияләгәндә, файдалануга тапшырганда һәм аларны эксплуатацияләгәндә экологик таләпләрне бозу**

Милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрне, корылмаларны, технологик линияләрне, җайланмаларны һәм башка төрле объектларны урнаштырганда, төзегәндә, реконструкцияләгәндә, эксплуатацияләгәндә, файдалануга тапшырганда һәм алардан файдаланганда экологик таләпләрне бозган өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең җиде минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

40 статья. **Җитештерү һәм куллану калдыкларын зарарсызландыру, урнаштыру, файдалы эшкә тоту яисә күмү кагыйдәләрен үтәмәү**

Җитештерү һәм куллану калдыкларын зарарсызландыру, файдалы эшкә тоту, урнаштыру яисә күмү кагыйдәләрен үтәмәгән өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга хезмәт өчен түләүнең ике минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең җиде минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

41 статья. **Радиоактив материаллардан, химик һәм башка төрле зарарлы матдәләрдән файдалану һәм аларны күмү кагыйдәләрен үтәмәү**

Радиоактив материаллардан, химик һәм башка зарарлы матдәләрдән файдалану һәм аларны күмү кагыйдәләрен үтәмәгән өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затлар-

га хезмәт өчен түләүнең ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

42 статья. **Җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерүнең һәм урнаштыруның билгеләнгән лимитларын арттыру**

Җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерүнең һәм урнаштыруның билгеләнгән лимитларын арттырган өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең унбиш минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең утыз минималь күләменә кадәр штраф салына.

43 статья. **Җитештерү һәм куллану калдыкларын, радиоактив калдыкларны барлыкка китерүнең һәм урнаштыруның дәүләт исәбе булмау һәм билгеләнгән хисапны тапшырмау**

Җитештерү һәм куллану калдыкларын, радиоактив калдыкларны барлыкка китерүнең һәм урнаштыруның дәүләт исәбе булмаган өчен һәм билгеләнгән хисапны тапшырмаган өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең өчтән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

44 статья. **Җитештерү һәм куллану калдыкларын шушы максатлар өчен махсус билгеләнмәгән урыннарда урнаштыру**

Җитештерү һәм куллану калдыкларын шушы максатлар өчен махсус билгеләнмәгән урыннарда урнаштырган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

45 статья. **Кар түгүләрне торак пунктларыннан читтә, билгеләнмәгән урыннарда оештыру**

Кар түгүләрне торак пунктларыннан читтә, билгеләнмәгән урыннарда оештырган өчен -

кисәтү ясала яисә урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә юридик затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

46 статья. **Әйләнә-тирә табигать мохитенең сыйфат стандартларын, нормаларын һәм башка төрле нормативларын үтәмәү**

Әйләнә-тирә табигать мохитенең сыйфат стандартларын, нормаларын һәм башка төрле нормативларын үтәмәгән өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

**47 статья. Атмосфера һавасына һәм су объектларына пычраткыч матдәләрне билгеләнгән нормативларны арттырып ташлау һәм бүлеп чыгару**

Атмосфера һавасына һәм су объектларына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларның, бүлеп чыгаруларның яисә аларны вакытлыча килештереп чыгарып ташлауларның, бүлеп чыгаруларның иң чик мөмкин нормативларын арттырган өчен -

кисәтү ясала яисә урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**48 статья. Шау-шуны, вибрацияне, магнит йогынтыларын иң чик мөмкин дәрәҗәдән арттыру**

Шау-шуны, вибрацияне, магнит йогынтыларын иң чик мөмкин дәрәҗәдән арттырган өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең унбиш минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең җитмеш биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

**49 статья. Халыкны радиацион нурландыруның иң чик мөмкин күләмен, әйләнә-тирә табигать мохитендә һәм азык-төлек продуктларында радиоактив матдәләр булуның хәвефсез дәрәҗәсен арттыру**

Халыкны радиацион нурландыруның иң чик мөмкин күләмен, әйләнә-тирә табигать мохитендә һәм азык-төлек продуктларында радиоактив матдәләр булуның хәвефсез дәрәҗәсен арттырган өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**50 статья. Озон катламы торышына зарарлы йогынты ясаучы химик матдәләрдән файдалануның билгеләнгән тәртибен бозу**

Озон катламы торышына зарарлы йогынты ясаучы химик матдәләрдән файдалануның билгеләнгән тәртибен бозган өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең унбиш минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең житмеш биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

51 статья. **Продукциягә карата экологик таләпләрне бозу**

Продукциягә карата әйләнә-тирә мохиткә йогынтыларның иң чик мөмкин нормативлары үтәлешен тәэмин итүче экологик таләпләрне бозган өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең унике минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең алтмыш минималь күләменә кадәр штраф салына.

52 статья. **Экологик нормаларга, гамәлдәге ГОСТ таләпләренә туры килми торган мотор ягулыгын житештерү һәм (яисә) реализацияләү**

Экологик нормаларга, гамәлдәге ГОСТ таләпләренә туры килми торган мотор ягулыгын житештергән һәм (яисә) реализацияләгән өчен -

кисәтү ясала яисә урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең унбиш минималь күләменә кадәр яки индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең житмеш биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

53 статья. **Санитар һәм башка төрле яклау зоналары режимын бозу**

Санитар һәм яклау зоналарының режимын, сулыкларны һәм су белән тәэмин итүнең башка төрле чыганакларын, курорт, дәвалау-сәламәтләндерү зоналарын, торак пунктларын һәм башка территорияләрне саклау режимын бозган өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең унбиш минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең житмеш биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

54 статья. **Автомототранспорт һәм башка йөрү чараларын һәм җайланмаларын пычраткыч матдәләрнең бөркелеп чыгучы нормативларын арттырып, шулай ук эшләп торгандагы шау-шу дәрәҗәсенең билгеләнгән нормативларын арттырып эксплуатацияләү**

Автомототранспорт һәм башка йөрү чараларын һәм җайланмаларын пычраткыч матдәләр бөркелеп чыгуның, шулай ук эшләп

торгандагы шау-шу дәрәҗәсенең билгеләнгән нормативларын арттырып эксплуатацияләгән өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

55 статья. **Самолетларны һәм судноларны пычраткыч матдәләрне нормативлардан артыграк бөркелеп чыгарган килеш эксплуатацияләүгә чыгарып җибәрү**

Самолетларны һәм судноларны пычраткыч матдәләрне нормативлардан артыграк бөркелеп чыгарган килеш, шулай ук эшләп торгандагы шау-шу дәрәҗәсенең билгеләнгән нормативларын арттырып эксплуатацияләүгә чыгарып җибәргән өчен -

кисәтү ясала яисә урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

56 статья. **Атмосферага бөркеп чыгаруларны чистарту һәм тикшереп тору җиһазларыннан файдалану кагыйдәләрен бозу**

Атмосферага бөркеп чыгаруларны чистарту һәм тикшереп тору җайланмаларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозган өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең җиде минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең утыз минималь күләменә кадәр штраф салына.

57 статья. **Атмосферага зарарлы матдәләрне бөркеп чыгаруларны чистарту җиһазларыннан файдаланмау**

Атмосферага зарарлы матдәләрне бөркеп чыгаруларны чистарту җиһазларыннан, шулай ук газ чистарту җиһазларыннан һәм контроль-үлчәү приборларыннан файдаланмаган өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең унбиш минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең алтмыш минималь күләменә кадәр штраф салына.

58 статья. **Җитештерү һәм куллану калдыкларын бер урынга туплаганда һәм яндырганда атмосфера һавасын саклау кагыйдәләрен һәм таләпләрен үтәмәү**

Җитештерү һәм куллану калдыкларын зарарсызландыру, яңадан эшкәртү, файдалы эшкә тоту, бер урынга туплау яисә күмү

корылмаларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм таләпләрен үтәмәгән, күрсәтелгән калдыкларны яндырганда атмосфера һавасын саклау таләпләрен үтәмәгән өчен -

кисәтү ясала яисә урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең унбиш минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең җитмеш биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

59 статья. **Предприятиегә, учреждениегә, оешмага беркетелгән территорияне экология стандартларын, ГОСТлар һәм сәнәгать санитариясе таләп ләрен бозган килеш тоту**

Предприятиегә, учреждениегә, оешмага беркетелгән территорияне экология стандартларын, ГОСТлар һәм сәнәгать-санитария стандартлары таләпләрен бозган килеш тоткан өчен -

кисәтү ясала яисә урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

Административ җәза гамәлләрен кулланганнан соң бер ел эчендә шул ук гамәлләрне кабат башкарган өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

60 статья. **Табигый байлыклардан рөхсәтсез (лицензиясез) файдалану**

Табигый байлыклардан файдалануга законнарда рөхсәт (лицензия) алу каралган булып та, шушы табигый байлыклардан рөхсәтсез (лицензиясез) файдаланган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

61 статья. **Дәүләт һәм җәмәгать экология контролен үткәрүгә каршылык күрсәтү**

Дәүләт һәм җәмәгать экология контролен үткәрүгә каршылык күрсәткән өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

**62 статья. Табигать мохитенең торышы турында, пычрату чыганаклары һәм радиацион хәл турында мәгълүмат бирү тәртибен бозу**

Табигать мохитенең торышы турында, пычрату чыганаклары һәм радиацион хәл турында вакытсыз яисә бозып күрсәтелгән мәгълүмат биргән өчен, шулай ук болар турында тулы һәм дөрес мәгълүмат бирүдән баш тарткан яисә каршылык күрсәткән өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең унбиш минималь күләменә кадәр штраф салына.

**63 статья. Әйләнә-тирә табигать мохитен пычраткан өчен түләүләрдән читләшү**

Әйләнә-тирә табигать мохитен пычрату күләмнәре турында һәм табигатьтән файдалану шартлары, шулай ук табигый байлыклардан файдалану күләмнәре турында күрәләтә бозып күрсәтелгән белешмәләрне бухгалтер һәм башка хисап документларына кертү юлы белән әйләнә-тирә табигать мохитен пычрату һәм табигый байлыклардан файдалану түләүләреннән читләшкән йә аларны күрсәтми калган өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

## II БҮЛЕК. ЭКОЛОГИК ЭКСПЕРТИЗА ӨЛКӘСЕНДӘ АДМИНИСТРАТИВ ХОКУК БОЗУЛАР

**64 статья. Экологик экспертиза таләпләрен үтәмәү**

Экологик экспертиза документларын бирмәгән, экологик экспертизага тапшырылучы керәкле материалларны, белешмәләрне һәм күрсәткечләрне, шулай ук аны үткәрү нәтиҗәләре турындагы белешмәләрне бирүдән читләшкән өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

**65 статья. Мәҗбүри дәүләт экологик экспертизасы узарга тиешле объектларны дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсеннән башка финанслау**

Милек рәвешләренә карамастан, мәҗбүри дәүләт экологик экспертизасы узарга тиешле объектларны дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсеннән башка банк учреждениеләре финанслаган өчен -

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

66 статья. **Экологик экспертиза экспертын күрәләтә ялган бәяләмә әзерләүгә этәрү, экологик эспертизаны оештыруга һәм үткәрүгә каршылыклар тудыру**

Экологик экспертиза экспертын күрәләтә ялган бәяләмә әзерләүгә этәргән, экологик эспертизаны оештыруга һәм үткәрүгә каршылыклар тудырган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

67 статья. **Дәүләт экологик экспертизасы объектын дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсеннән башка реализацияләү**

Дәүләт экологик экспертизасы объектын дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсеннән башка реализацияләгән өчен -

кисәтү ясала яисә гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

68 статья. **Дәүләт экологик экспертизасы, эксперт комиссиясе һәм экспертлау өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы эшенә хокукка каршы катышу**

Дәүләт экологик экспертизасы, эксперт комиссиясе һәм экспертлау өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы эшенә экологик эспертиза үткәрү барышына һәм нәтиҗәләренә йогынты ясау максатларында хокукка каршы катышкан өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

69 статья. **Җәмәгать экологик экспертизасын уздыру турындагы гаризаларны дәүләт теркәвенә алудан законсыз баш тарту**

Җәмәгать экологик экспертизасын уздыру турындагы гаризаларны дәүләт теркәвенә алудан законсыз баш тарткан өчен -

кисәтү ясала яисә урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

**70 статья. Дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсен алган документларга туры килми торган хуҗалык эшчәнлеген һәм башка төрле эшчәнлекне башкару**

Дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсен алган документларга туры килми торган хуҗалык эшчәнлеген һәм башка төрле эшчәнлекне башкарган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең унбиш минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең җитмеш биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

**71 статья. Дәүләт экологик экспертизасы уңай бәяләмәсенең гамәлдә булу чоры узганнан соң дәүләт экологик экспертизасы объектларын реализацияләү**

Дәүләт экологик экспертизасы уңай бәяләмәсенең гамәлдә булу чоры узганнан соң дәүләт экологик экспертизасы объектларын реализацияләгән өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең унбиш минималь күләменә кадәр яисә индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга хезмәт өчен түләүнең җитмеш биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

**72 статья. Дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе булмаган килешү, әйләнә-тирә табигать мохитенә турыдан-туры яисә читләтеп йогынты ясарлык итеп табигатьтән файдалануга яисә башка төрле эшчәнлекне башкаруга лицензия бирү**

Дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе булмаган килешү, әйләнә-тирә табигать мохитенә турыдан-туры яисә читләтеп йогынты ясарлык итеп табигатьтән файдалануга яисә башка төрле эшчәнлек башкаруга лицензия биргән өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

## III бүлек. Административ экологик хокук бозулар турындагы эшләрнең ведомстволы булуы

**73 статья. Административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр**

Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр Татарстан Республикасының Эчке эшләр

министрлыгының, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтчелеге дәүләт комитетының, Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый байлыклар министрлыгының, Татарстан Республикасының Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт комитетының, Татарстан Республикасының Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча дәүләт комитетының, Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгының, дәүләт идарәсенең законнар белән вәкаләт тапшырылган башка төрле органнарының шуңа вәкаләтле урындагы затлары тарафыннан административ хокук бозулар турындагы законнар нигезендә төзеләләр.

**74 статья. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау**

Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда каралалар.

**75 статья. Шәһәр, район судлары**

Шәһәр, район судлары әлеге Законның 62 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карыйлар.

**76 статья. Эчке эшләр органнары**

Эчке эшләр органнары әлеге Законның 22,45 һәм 54 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карыйлар.

Эчке эшләр органнарының территория бүлекчәләре башлыклары һәм башлык урынбасарлары эчке эшләр органнары исеменнән административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга һәм административ җәзалар бирергә хокуклы.

**77 статья. Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтчелеге дәүләт комитеты**

Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтчелеге дәүләт комитеты, аның урыннардагы органнары әлеге Законның 41,44,46,48,49,51 һәм 53 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне үз компетенцияләре чикләрендә карыйлар.

Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтчелеге органнары исеменнән административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга һәм административ җәзалар бирергә түбәндәгеләр хокуклы:

Татарстан Республикасының баш дәүләт санитария табибе, аның урынбасарлары, Татарстан Республикасы шәһәрләренең һәм

районнарының баш дәүләт санитария табибләре, аларның урынбасарлары.

78 статья. **Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый байлыклар министрлыгы**

Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый байлыклар министрлыгы әлеге Законның 1, 3-9, 13, 16-19, 24,55,26 статьяларында (дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли табигать парклары территорияләрендә башкарылган административ хокук бозулардан гайре), 27-35, 38-49, 53-61, 63-72 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карый.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән органнар исеменнән административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга һәм административ җәзалар бирергә түбәндәгеләр хокуклы:

Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча баш дәүләт инспекторы, аның урынбасарлары;

Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча баш дәүләт инспекторлары - үз эшчәнлекләре зоналарында, аларның урынбасарлары.

79 статья. **Хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануны саклау, тикшереп тору һәм җайга салу органнары**

Хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануны саклау, тикшереп тору һәм җайга салу органнары әлеге Законның 28-37 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карый.

Хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануны саклау, тикшереп тору һәм җайга салу буенча дәүләт инспекторлары хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануны саклау, тикшереп тору һәм җайга салу органнары исеменнән административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга һәм административ җәзалар бирергә хокуклы.

80 статья. **Татарстан Республикасының Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт комитеты**

Татарстан Республикасының Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт комитеты, аның урыннардагы органнары әлеге Законның 59 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карыйлар.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән органнар исеменнән административ хокук бозулар турындагы эшләрне

карарга һәм административ җәзалар бирергә түбәндәгеләр хокуклы:

Татарстан Республикасының җирләрдән файдалану һәм аларны саклау буенча баш дәүләт инспекторы, аның урынбасарлары;

Татарстан Республикасы, шәһәрләр, районнар җирләреннән файдалану һәм аларны саклау буенча дәүләт инспекторлары һәм аларның урынбасарлары.

**81 статья. Татарстан Республикасының Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану дәүләт комитеты**

Татарстан Республикасының Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану дәүләт комитеты әлеге Законның 1 һәм 2 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карый.

Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган органнар исеменнән административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга һәм административ җәзалар бирергә түбәндәгеләр хокуклы:

Татарстан Республикасының геология тикшереп торуы буенча баш дәүләт инспекторы, аның урынбасарлары;

Татарстан Республикасының геология тикшереп торуы буенча дәүләт инспекторлары.

**82 статья. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы**

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы әлеге Законның 10-18, 20-23 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карый.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы исеменнән административ хокук бозуларны карарга һәм административ җәзалар бирергә түбәндәгеләр хокуклы:

Татарстан Республикасында урманнарның торышын, алардан файдалануны, аларны яңартуны, саклауны һәм яклауны тикшереп тору буенча баш дәүләт инспекторы;

Татарстан Республикасында урманнарның торышын, алардан файдалануны, аларны яңартуны, саклауны һәм яклауны тикшереп тору буенча өлкән дәүләт инспекторлары;

Татарстан Республикасында урманнарның торышын, алардан файдалануны, аларны яңартуны, саклауны һәм яклауны тикшереп тору буенча дәүләт инспекторлары;

урман хуҗалыклары эшчәнлеге зонасында урманнарның торышын, алардан файдалануны, аларны яңартуны, саклауны һәм яклауны тикшереп тору буенча өлкән дәүләт инспекторлары, аларның урынбасарлары;

урман хуҗалыклары эшчәнлеге зонасында урманнарның торышын, алардан файдалануны, аларны яңартуны, саклауны һәм яклауны тикшереп тору буенча дәүләт инспекторлары.

83 статья. **Дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли табигать парклары**

Дәүләт табигать тыюлыкларының һәм милли табигать паркларының урындагы вәкаләтле затлары әлеге Законның 26 статьясында каралган һәм тиешле дәүләт табигать тыюлыкларының һәм милли табигать паркларының территорияләрендә башкарылган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карыйлар.

### IV бүлек. Йомгак нигезләмәләр

84 статья. **Штрафларның суммаларын бүлү**

Әлеге Закон нигезендә алынган штрафларның суммалары Татарстан Республикасы Экология фондының махсус (бюджет) счетына җибәрелә.

Штрафларның алынган суммасыннан 50 процентына кадәре хокук бозуны ачкан органның матди-техник базасын ныгыту өчен Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына җибәрелә.

Дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли табигать парклары территорияләрендә башкарылган әлеге Законның 26 статьясында каралган административ хокук бозулар өчен алынган штрафларның суммалары законнарда билгеләнгән тәртиптә кулланылалар.

85 статья. **Әлеге Законны гамәлгә кертү турында**

Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2280

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 662. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре турында

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. **Әлеге Законның бурычлары һәм кулланылыш өлкәсе**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен төзү, үтәү һәм туктату тәртибен билгели. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре халыкара хокукның го-

мумтанылган принциплары һәм нормалары, Татарстан Республикасы Конституциясе, шартнамәнең үз нигезләмәләре, әлеге Закон нигезендә төзеләләр, үтәләләр һәм туктатылалар.

2. Әлеге Закон, төрләренә һәм исемнәренә (шартнамә, килешү, беркетмә, хатлар алмашу, халыкара шартнамәләрнең бүтән төрләренә һәм исемнәренә) карамастан, Татарстан Республикасының барлык халыкара шартнамәләренә (дәүләтара, парламентара, хөкүмәтара һәм ведомствоара шартнамәләргә) карата кулланыла.

2 статья. **Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр**

Әлеге Законның максатлары өчен:

а) «Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсе» - Татарстан Республикасы белән чит дәүләт (яисә чит дәүләтләр), чит федератив дәүләтләрнең субъектлары, чит дәүләтләрнең административ-территория төзелмәләре йә халыкара оешма арасында язма рәвештә төзелүче һәм, килешүнең бер документта яки үзара бәйләнешле берничә документта булуына, шулай ук аның төгәл исеменә бәйсез рәвештә, халыкара хокук тарафыннан җайга салынучы халыкара килешү;

б) «Татарстан Республикасының дәүләтара шартнамәсе» - Татарстан Республикасы белән чит дәүләт яисә берничә чит дәүләт арасында аерым вакытка яисә вакыты чикләнмичә төзелгән килешү;

в) «парламентара шартнамә» - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән башка дәүләт парламенты йә халыкара парламент оешмалары арасында язма рәвештә төзелгән парламентара килешү;

г) «хөкүмәтара шартнамә» - Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты белән чит дәүләт хөкүмәте йә халыкара оешма арасында язма рәвештә төзелгән хөкүмәтара килешү;

д) «ведомствоара шартнамә» - Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары белән чит дәүләтнең тиешле дәүләт органы йә халыкара оешма арасында язма рәвештә төзелгән ведомствоара килешү;

е) «ратификацияләү», «раслау», «кабул итү» һәм «кушылу» - очракка бәйле рәвештә Татарстан Республикасының үзе өчен халыкара шартнамәнең мәҗбүри булуына ризалыгын белдерү рәвеше;

ж) «имза салу» - шартнамә төзү стадиясе йә, әгәр шартнамәдә имза салу мәҗбүрилек көченә ия булса яисә мәҗбүрилек көченә ия булу турында яки, Татарстан Республикасының имза салуга мәҗбүрилек төсе бирү нияте аның вәкиленең вәкаләтләренә бәйле булып, Татарстан Республикасы белән сөйләшүләрдә катнашучы бүтән дәүләтләр арасында башкача килешенгән булса, йә бу хакта

сөйләшүләр барышында белдерелгән булса, үзе өчен халыкара шартнаманең мәҗбүри булуына Татарстан Республикасының ризалык белдерү рәвеше;

з) «төзү» - үзе өчен халыкара шартнаманең мәҗбүри булуына Татарстан Республикасының ризалык белдерүе;

и) «вәкаләтләр» - Татарстан Республикасының компетенцияле органыннан чыккан һәм шуның ярдәмендә бер яисә берничә затның түбәндәге максатларда Татарстан Республикасы исеменнән эш йөртүен билгели торган документ: сөйләшүләр алып бару өчен; шартнамә текстын кабул итү яисә аның аутентлыгын билгеләү өчен; үзе өчен шартнаманең мәҗбүри булуына Татарстан Республикасының ризалык белдерүе өчен; шартнамәгә кагылышлы теләсә нинди башка актны башкару өчен;

к) «искәрмә» - шартнамәгә имза салганда, аны ратификацияләгәндә, раслаганда, кабул иткәндә яисә аңа кушылганда ясалган берьяклы белдерү, аның аша шартнаманең кайбер нигезләмәләрен Татарстан Республикасына карата кулланудагы юридик көчен юкка чыгару яисә үзгәртү теләге белдерелә;

л) «халыкара оешма» - дәүләтара яисә хөкүмәтара оешма;

м) «депозитарий» - халыкара шартнаманең төп нөсхәсе саклануга бирелә торган һәм халыкара хокукта каралган вазыйфаларны әлеге шартнамәгә карата башкаручы дәүләт, халыкара оешма яисә аның төп башкаручы урындагы заты йә вәкаләтле дәүләт органы;

н) «денонсация» - ике яклы халыкара шартнаманең гамәлдә булуын туктату яисә шартнамәдә билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта күпьяклы халыкара шартнамәдән чыгу алымы.

3 статья. **Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен төзегәндә Татарстан Республикасы компетенциясе**

1. Татарстан Республикасы, халыкара хокук принципларына таянып, башка дәүләтләр белән мөнәсәбәтләр урнаштыра, халыкара шартнамәләр төзи, дипломатик, консуллык, сәүдә һәм башка вәкиллекләр белән алмаша, халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнаша. Халыкара хокукның гомум танылган принциплары һәм нормалары Татарстан Республикасы законнарыннан өстен була.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары халыкара мөнәсәбәтләрдә катнашалар, чит дәүләтләр белән бәйләнешләр урнаштыралар һәм алар белән Россия Федерациясе Конституциясенә һәм халыкара йөкләмәләренә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, «Россия Федерациясе дәүләт ха-

кимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсенә каршы килмәслек килешүләр төзиләр, тиешле халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнашалар.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары карамагына кертелгән мәсьәләләргә кагылучы Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләре дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле җирле органнары белән килешенеп төзеләләр.

4 статья. **Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең төрләре**

Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләре чит дәүләтләр, чит федератив дәүләтләрнең субъектлары, чит дәүләтләрнең административ-территория төзелмәләре, халыкара оешмалар белән Татарстан Республикасы исеменнән (дәүләтара шартнамәләр), Татарстан Республикасы Дәүләт Советы исеменнән (парламентара шартнамәләр), Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты исеменнән (хөкүмәтара шартнамәләр), Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары исеменнән (ведомствоара шартнамәләр) төзеләләр.

5 статья. **Үзе өчен халыкара шартнамәнең мәҗбүри булуына Татарстан Республикасының ризалык белдерүе**

1. Үзе өчен халыкара шартнамәнең мәҗбүри булуына Татарстан Республикасының ризалыгы түбәндәге юллар аша белдерелергә мөмкин:

шартнамәгә имза салу;

шартнамәне барлыкка китерүче документлар алмашу;

шартнамәне ратификацияләү;

шартнамәне раслау;

шартнамәне кабул итү;

шартнамәгә кушылу;

ризалык белдерүнең сөйләшүче яклар билгеләгән теләсә нинди башка алымын куллану.

2. Үзе өчен халыкара шартнамәләрнең мәҗбүри булуына Татарстан Республикасының ризалык белдерүе турындагы карарларны Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары Татарстан Республикасы Конституциясендә, әлеге Законда, Татарстан Республикасының бүтән закон актларында билгеләнгән компетенцияләре нигезендә кабул итәләр.

**6 статья. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мәгълүмат бирү**

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты Татарстан Республикасы исеменнән һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты исеменнән төзелгән Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләре турында, шулай ук мондый шартнамәләрне туктату яисә аларның гамәлдә булуын туктатып тору хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мәгълүмат бирәләр.

## II БҮЛЕК. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ХАЛЫКАРА ШАРТНАМӘЛӘРЕН ТӨЗҮ

**7 статья. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен төзү турында рекомендацияләр**

1. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен төзү турындагы рекомендацияләр, кагылучы мәсьәләләрнең асылыннан чыгып, Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каравына кертелергә мөмкин.

Мондый рекомендацияләр Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасы Югары суды, Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды, Татарстан Республикасы Прокуроры, Татарстан Республикасы Милли банкы тарафыннан да кертелергә мөмкин.

2. Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты яисә алар кушуы буенча Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең тиешле органы җитәкчесе бер ай эчендә рекомендациягә җавап бирәләр.

**8 статья. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен төзү турында тәкъдим**

1. Татарстан Республикасы исеменнән халыкара шартнамәләр төзү турындагы тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Президентына кертеләләр.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы исеменнән халыкара шартнамәләр төзү турындагы тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертеләләр.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты исеменнән халыкара шартнамәләр төзү турындагы тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына кертеләләр.

Татарстан Республикасының ведомствоара халыкара шартнамәләрен төзү турындагы тәкъдимнәр, дәүләт идарәсенең кайсы органнары компетенциясенә караса, шул органнар тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына кертеләләр.

2. Халыкара шартнамә төзү турындагы тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына яисә Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсенең кызыксынучы органнары тарафыннан кертеләләр.

3. Халыкара шартнамә төзү турындагы тәкъдимнәрдә шартнамәнең проекты яисә аның төп нигезләмәләре, аны төзүнең максатка ярашлылыгын дәлилләү, шартнамә проектының Татарстан Республикасы законнарына туры килүен билгеләү, шулай ук шартнамә төзегәннән соң ихтимал булган финанс-икътисадый һәм башка нәтиҗәләргә бәяләү булырга тиеш.

**9 статья. Сөйләшүләр уздыру һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләренә имза салу турындагы карарлар**

Сөйләшүләр уздыру һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләренә имза салу турындагы карарлар түбәндәгеләр тарафыннан кабул ителәләр:

а) Татарстан Республикасы исеменнән төзелүче шартнамәләргә карата - Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан;

б) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы исеменнән төзелүче шартнамәләргә карата - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан;

в) Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты исеменнән төзелүче шартнамәләргә карата - Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан;

г) ведомствоара шартнамәләргә карата - Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты белән килешеп, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең кызыксынучы органнары тарафыннан.

**10 статья. Вәкаләтләрен дәлилләп тормастан сөйләшүләр алып бару һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләренә имза салу**

1. Татарстан Республикасы Президенты, вәкаләтләрен дәлилләп тормастан, дәүләт башлыгы буларак Татарстан Республикасы Кон-

ституциясе һәм халыкара хокук принциплары нигезендә халыкара багланышларда Татарстан Республикасы исеменнән эш йөртә, сөйләшүләр алып бара һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләренә имза сала.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, вәкаләтләрен дәлилләп тормастан, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының иң югары урындагы заты буларак башка дәүләтләрнең парламентлары белән багланышларда Дәүләт Советы исеменнән эш йөртә, сөйләшүләр алып бара һәм парламентара шартнамәләргә имза сала.

3. Татарстан Республикасы Премьер-министры, вәкаләтләрен дәлилләп тормастан, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты вәкаләтләре чикләрендә сөйләшүләр алып бара һәм халыкара хөкүмәтара шартнамәләргә имза сала.

4. Министр, дәүләт комитеты рәисе, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең башка органы җитәкчесе үз компетенциясе чикләрендә, вәкаләтләрен дәлилләп тормастан, сөйләшүләр алып барырга һәм ведомствоара шартнамәләргә имза салырга хокуклы.

5. Татарстан Республикасының чит дәүләттәге вәкиллеге башлыгы яисә халыкара оешма каршындагы Татарстан Республикасы вәкиллеге башлыгы, вәкаләтләрен дәлилләп тормастан, халыкара шартнамә текстын кабул итү максатларында сөйләшүләр алып барырга хокуклы.

11 статья. **Сөйләшүләр алып бару һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләренә имза салу вәкаләтләре**

Сөйләшүләр алып бару һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләренә имза салу вәкаләтләре түбәндәгеләр тарафыннан бирелә:

а) Татарстан Республикасы исеменнән төзелүче шартнамәләргә карата - Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан;

б) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы исеменнән төзелүче шартнамәләргә карата - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан;

в) Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты исеменнән төзелүче шартнамәләргә карата - Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан;

г) ведомствоара шартнамәләргә карата - Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең тиешле органы җитәкчесе тарафыннан.

**12 статья. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен ратификацияләү**

1. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы ратификацияли.

2. Татарстан Республикасының түбәндәге халыкара шартнамәләре ратификацияләнергә тиеш:

а) үтәлешләре гамәлдәге законнарның үзгәртелүен яисә яңа законнар кабул итүне таләп итүче, шулай ук Татарстан Республикасы законында каралганнан бүтәнрәк нормалар билгеләүче;

б) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекен җайга салу предметы булучы;

в) халыкара нигезләр һәм тышкы икътисадый багланышлар турындагы;

г) Татарстан Республикасының дәүләтара берлекләрдә, халыкара оешмаларда һәм бүтән берләшмәләрдә катнашуы турындагы, әгәр мондый шартнамәләрдә Татарстан Республикасы вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру аларга тапшыру күздә тотылган булса яисә Татарстан Республикасы өчен аның органнары карарларының юридик мәҗбүрилеге билгеләнгән булса.

3. Төзегәндә яклар соңыннан аларны ратификацияләү турында килешкән Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләре дә ратификацияләнергә тиеш.

**13 статья. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен ратификацияләүгә кертү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы исеменнән имзаланган Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советына ратификацияләү өчен Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертеләләр.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты исеменнән имзаланган Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советына ратификацияләү өчен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан кертеләләр.

Кирәк очракта, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты хөкүмәтара шартнамәне ратификацияләүгә кертү турындагы тәкъдимне Татарстан Республикасы Президентына тапшырырга хокуклы.

2. Халыкара шартнамәне ратификацияләү турындагы тәкъдимдә рәсми шартнамә текстының таныкланган күчермәсе, халыкара шартнамәне ратификацияләү турында Татарстан Республикасы законы проекты, аны ратификацияләүнең максатка яраш-

лылыгын дәлилләү, шартнамәнең Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвен билгеләү, шартнамәне ратификацияләүнең ихтимал булган финанс-икътисадый һәм башка нәтиҗәләренә бәяләү булырга тиеш.

14 статья. **Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен ратификацияләү турындагы карарлар**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы халыкара шартнамәләрне ратификацияләү турындагы тәкъдимнәрне карый һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләрендә алар буенча алдан фикер алышулар уздырганнан соң тиешле закон кабул итә.

2. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсен ратификацияләү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кабул иткән закон имза салу өчен Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

15 статья. **Ратификацияләү грамотасына имза салу**

Татарстан Республикасы халыкара шартнамәсен ратификацияләү турында Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты ратификацияләү грамотасына имза сала, аңа Татарстан Республикасы Президентының герб төшерелгән мөһере сугыла.

16 статья. **Ратификацияләү грамоталарын алмашу һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен ратификацияләү турындагы грамоталарны депозитарийларга саклау өчен тапшыру**

Ратификацияләү грамоталарын алмашу һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен ратификацияләү турындагы грамоталарны депозитарийларга саклау өчен тапшыруны Татарстан Республикасы Президенты вәкаләт биргән орган башкара.

17 статья. **Халыкара шартнамәләрне раслау, кабул итү**

1. Расланырга, кабул ителергә тиешле халыкара шартнамәләрне раслау, кабул итү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

а) әлеге Законның 12 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы исеменнән төзелүче шартнамәләргә карата - шартнамәләрне ратификацияләү өчен әлеге Законның 14 статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Законы рәвешендә;

б) Татарстан Республикасы исеменнән төзелүче шартнамәләргә карата (әлеге пунктның «а» пунктчасында каралган шартнамәләрдән гайре) - Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан;

в) Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты исеменнән төзелүче шартнамәләргә карата - Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан.

2. Ведомствоара халыкара шартнамәләр расланганнан соң, кабул ителгәннән соң үз көченә керәсе булса, аларны раслауны, кабул итүне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты гамәлгә ашыра.

3. Татарстан Республикасы законы рәвешендәге халыкара шартнамәләрне раслау, кабул итү турындагы тәкъдимнәр - әлеге Законның 13 статьясында билгеләнгән тәртиптә, ә калган очракларда әлеге Законның 8 статьясында каралган тәртиптә биреләләр.

18 статья. **Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләргә кушылуы**

1. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләргә кушылуы турындагы карар түбәндәгечә кабул ителә:

а) әлеге Законның 12 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча кушылу Татарстан Республикасы исеменнән гамәлгә ашырыла торган шартнамәләргә карата - әлеге Законның 14 статьясында халыкара шартнамәләрне ратификацияләү өчен билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы законы рәвешендә;

б) кушылу Татарстан Республикасы исеменнән гамәлгә ашырыла торган шартнамәләргә карата (әлеге пунктның «а» пунктчасында каралган шартнамәләрдән тыш) - Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан;

в) кушылу Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты исеменнән гамәлгә ашырыла торган шартнамәләргә карата - Татарстан Республикасы Президенты яисә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карамагына керүче мәсьәләләр буенча халыкара шартнамәләргә кушылу турындагы карарны, әгәр ул зарурый булса, Татарстан Республикасы Президенты кабул итә.

3. Ведомствоара халыкара шартнамәләргә кушылу әлеге Законның 9 статьясындагы «г» пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Халыкара шартнамәләргә Татарстан Республикасы законы рәвешендә кушылу турындагы тәкъдимнәр - әлеге Законның

13 статьясында билгеләнгән тәртиптә, калган очракларда әлеге Законның 8 статьясында каралган тәртиптә биреләләр.

**19 статья. Халыкара шартнамәләрнең Татарстан Республикасы өчен мәҗбүри булуына ризалык белдерүнең махсус тәртибе**

Әгәр халыкара шартнамәдә Татарстан Республикасы Конституциясенең кайбер нигезләмәләрен үзгәртүне таләп итүче кагыйдәләр булса, үзе өчен аның мәҗбүри булуына Татарстан Республикасының ризалык белдерүе турындагы карар, Татарстан Республикасы Конституциясенә билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертелгәннән соң гына, Татарстан Республикасы законы рәвешендә кабул ителергә мөмкин.

**20 статья. Халыкара шартнамәне Татарстан Республикасының вакытлыча куллануы**

1. Әгәр шартнамәдә каралган булса яисә шартнамәгә имза салучы яклар арасында үзара килешенгән булса, халыкара шартнамә яисә шартнамәнең аерым өлеше үз көченә кергәнче, аны Татарстан Республикасы вакытлыча куллана ала.

2. Халыкара шартнамәне яисә аның аерым өлешен Татарстан Республикасының вакытлыча куллануы турындагы карарны шартнамәгә имза салу турында карар кабул иткән орган әлеге Законның 9 статьясында билгеләнгән тәртиптә кабул итә.

Әгәр Татарстан Республикасының халыкара шартнамәнең үзе өчен мәҗбүри булуына ризалык белдерүе турындагы карары Татарстан Республикасы законы рәвешендә әлеге Закон нигезендә кабул ителергә тиеш булса, халыкара шартнамәне йә аның аерым өлешен вакытлыча куллану халыкара шартнамәдә күздә тотылса йә бу хакта яклар арасында бүтән рәвешле килешүгә ирешү булса, халыкара шартнамә, вакытлыча кулланыла башлаган көненнән алты айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшырыла. Татарстан Республикасы законы рәвешендә кабул ителгән карар буенча, шартнамәләрне ратификацияләү өчен әлеге Законның 14 статьясында билгеләнгән тәртиптә вакытлыча куллану чоры озайтылырга мөмкин.

3. Әгәр халыкара шартнамәдә башкасы күздә тотылмаса йә яклар бүтәнчә килешмәгән булсалар, шартнамәне яисә аның аерым өлешен Татарстан Республикасының вакытлыча куллануы, шартнамәне вакытлыча кулланучы башка дәүләтләргә Татарстан Республикасының шартнамәдә катнашырга нияте булмавы хакында хәбәр ителгәч, туктатыла.

21 статья. **Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең үз көченә керүе**

1. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре Татарстан Республикасы өчен шушы шартнамәдә каралган яисә имза салучы яклар билгеләгән тәртиптә һәм вакытларда үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең үз көченә керүе турындагы рәсми хәбәрләр әлеге Законның 24 статьясында каралган тәртиптә бастырып чыгарыла.

22 статья. **Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләренә искәрмәләр**

1. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләренә имза салганда, аларны ратификацияләгәндә, раслаганда, кабул иткәндә яисә шартнамәләргә кушылганда, шартнамә шартлары һәм халыкара хокукның тиешле нормалары үтәлгән килеш, искәрмәләр ясалырга мөмкин.

2. Әгәр Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, искәрмәләр, нинди тәртиптә кертелгән булсалар, шул ук тәртиптә теләсә кайсы вакытта төшереп калдырылырга мөмкин.

3. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсенә карата килешүче якларның берәрсе тарафыннан кертелүче искәрмәне кабул итү яисә аны кире кагу үзе өчен халыкара шартнамәнең мәҗбүри булуына Татарстан Республикасының ризалык белдерүе турындагы карарны кабул итүче орган тарафыннан шартнамәнең үз шартлары һәм халыкара хокук нормалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы законы рәвешендә бирелүче искәрмәләрне кабул итү яисә аларны кире кагу турындагы тәкъдимнәр - әлеге Законның 13 статьясында билгеләнгән тәртиптә, калган очракларда әлеге статьяның 8 статьясында каралган тәртиптә биреләләр. III бүлек. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен теркәү һәм рәсми бастырып чыгару

23 статья. **Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен теркәүнең һәм исәпкә алуның бердәм дәүләт системасы**

Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен теркәүнең һәм исәпкә алуның бердәм дәүләт системасы Татарстан Республикасы Президенты вәкаләт биргән орган карамагында була.

24 статья. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен рәсми бастырып чыгару

1. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрнең үзе өчен мәҗбүри булуына ризалык белдерүе турында закон рәве-

шендә кабул ителгән карары булган һәм Татарстан Республикасы өчен үз көченә кергән халыкара шартнамәләр рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

2. Халыкара ведомствоара шартнамәләр аларны төзегән дәүләт идарәсе органнарының карары буенча үзләренең рәсми басмаларында бастырып чыгарыла.

25 статья. Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең текстларын саклау

1. Татарстан Республикасы исеменнән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы исеменнән һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты исеменнән төзелгән Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең төп нөсхәләре (таныкланган күчермәләре, рәсми тәрҗемәләре) имза салынган (таныкланган күчермәләр, рәсми тәрҗемәләр депозитарийдан алынган) көннән башлап ике атна эчендә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләт биргән органга саклау өчен тапшырыла, ә бу шартнамәләрнең күчермәләре үз көченә кергән көннән башлап ике атна эчендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле органнарына җибәрелә.

2. Татарстан Республикасы халыкара ведомствоара шартнамәләренең төп нөсхәләре дәүләт идарәсенең тиешле органнары архивларында саклана, ә бу шартнамәләрнең таныкланган күчермәләре имза салынган (таныкланган күчермәләр, рәсми тәрҗемәләр депозитарийдан алынган) көннән соң ике атна эчендә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләт биргән органга җибәрелә.

26 статья. Депозитарий вазыйфаларын башкару

1. Әгәр күпкырлы халыкара шартнамәләрнең шартларында депозитарий вазыйфалары Татарстан Республикасына йөкләнгән булса, Татарстан Республикасының Президенты вәкаләт биргән орган күпкырлы халыкара шартнамәләрнең депозитарий вазыйфаларын гамәлгә ашыра.

2. Күпкырлы халыкара шартнамәләрнең депозитарий вазыйфаларын башкаручы чит дәүләтләр органнары белән, халыкара оешмалар яисә аларның башкарма урындагы баш затлары белән хәбәрләшү Татарстан Республикасы Президенты вәкаләт биргән орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## IV бүлек. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен үтәү

### 27 статья. **Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен үтәү**

1. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсе халыкара шартнамә шартлары, халыкара хокукның гомум танылган

принциплары һәм нормалары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, бүтән норматив-хокукый актлар нигезендә намус белән үтәлергә тиеш.

2. Татарстан Республикасы өчен халыкара шартнамә үз көченә кергәнче, халыкара хокукның тиешле нормаларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы шартнамәне аның объектыннан һәм максатыннан мәхрүм итәрлек гамәлләр кылудан тыелып тора.

3. Халыкара шартнамә Татарстан Республикасы өчен үз көченә кергән мизгелдән Татарстан Республикасы тарафыннан үтәлергә тиеш.

28 статья. **Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең үтәлешен тәэмин итү**

1. Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрәләр.

2. Үз компетенциясенә Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре белән җайга салынучы мәсьәләләр кергән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары шартнамәләр буенча үз йөкләмәләрен үтәүне һәм бу шартнамәләрдән килеп чыга торган үз хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәләр, шулай ук шартнамәләрдә катнашучы бүтәннәрнең үз йөкләмәләрен үтәүләрен күзәтеп торалар.

29 статья. **Башка катнашучылар Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсен бозганда күрелүче чаралар**

Башка катнашучылар Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсендәге йөкләмәләрне бозганда, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле органнары, шартнамә белән җайга салынучы мәсьәләләр кем компетенциясендә булуына карап, халыкара хокук нормалары һәм шартнамәнең үз шартлары нигезендә тиешле чаралар күрү турында Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына тәкъдимнәр бирәләр.

30 статья. **Халыкара шартнамәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве**

1. Татарстан Республикасының Конституция суды Татарстан Республикасының үз көченә кермәгән халыкара шартнамәләренең йә аларның аерым нигезләмәләренең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы эшләрне билгеләнгән тәртиптә хәл итә.

2. Татарстан Республикасының Конституция суды тарафыннан Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танылган Татарстан Республикасының үз көченә кермәгән халыкара шартнамәләре яисә аларның аерым өлешләре гамәлгә яисә куллануга кертелми.

## V бүлек. Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең гамәлдә булуын туктату һәм туктатып тору

**31 статья. Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору турында рекомендацияләр**

1. Әлеге Законның 7 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән субъектлар, шартнамә белән җайга салынучы мәсьәләләрнең кем компетенциясендә булуына карап, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каравына Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору турында рекомендацияләр бирә алалар.

2. Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты яисә аларның кушуы буенча дәүләт идарәсенең тиешле органы бер ай эчендә рекомендацияләргә җавап бирәләр.

**32 статья. Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору турында тәкъдимнәр**

1. Татарстан Республикасы исеменнән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы исеменнән һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты исеменнән төзелгән Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору турындагы тәкъдимнәр, Татарстан Республикасы өчен шартнамәнең мәҗбүри булуына ризалык белдерү турындагы карар кем тарафыннан кабул ителүгә карап, Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына яисә Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына тапшырыла.

2. Шартнамәләрнең мәҗбүри булуына Татарстан Республикасының ризалык белдерүе турындагы карары Татарстан Республикасы законы рәвешендә кабул ителгән Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору турындагы тәкъдимнәр, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының тиешле халыкара шартнамәне ратификацияләү турындагы Законны кем-

нең тәкъдименә нигезләнеп кабул итүенә карап, Татарстан Республикасы Президенты яисә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелә.

Әгәр кирәк булса, үзе өчен шартнамәләрнең мәҗбүри булуына Татарстан Республикасының ризалык белдерүе турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тәкъдиме нигезендә закон рәвешендә кабул ителгән карары булган Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору турында Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдимнәр кертә.

Кирәк чакта, үзе өчен шартнамәнең мәҗбүри булуына Татарстан Республикасының ризалык белдерүе турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты күрсәтмәсе нигезендә закон рәвешендә кабул ителгән карары булган Татарстан Республикасы халыкара шартнамәсенең гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим кертүе хакында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

3. Татарстан Республикасы халыкара шартнамәсенең гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору турындагы тәкъдимдә рәсми шартнамә текстының таныкланган күчермәсе, аның гамәлдә булуын туктатуның яисә туктатып торуның максатка ярашлылыгын нигезләү, шартнамәнең гамәлдә булуын туктатуның яисә туктатып торуның мөмкин булган финанс-икътисадый һәм башка нәтиҗәләрен бәяләү булырга тиеш.

33 статья. **Татарстан Республикасы халыкара шартнамәсенең гамәлдә булуын туктату һәм туктатып тору**

1. Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең гамәлдә булуын туктату (шул исәптән денонсация) һәм туктатып тору үзе өчен шартнамәнең мәҗбүри булуына Татарстан Республикасының ризалык белдерүе турындагы карарны кабул иткән орган тарафыннан шартнамәнең үз шартлары һәм халыкара хокук нормалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Кирәк булса, Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы өчен шартнамәләрнең мәҗбүри булуына Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан ризалык бирелгән Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору турында карарлар кабул итә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләрендә алдан фикер алышулар уздырганнан соң, Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору турындагы тәкъдимнәрне карый һәм тиешле карарлар кабул итә.

Татарстан Республикасы халыкара шартнамәсенең гамәлдә булуын туктату (шул исәптән денонсация) яисә туктатып тору турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителгән закон имза салу өчен Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

4. Татарстан Республикасының халыкара ведомствоара шартнамәләренең гамәлдә булуын туктату һәм туктатып тору Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең шартнамәләрне төзегән тиешле органнары тарафыннан һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты рөхсәте белән башкарыла.

5. Татарстан Республикасының халыкара ведомствоара шартнамәләренең гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору Татарстан Республикасының дәүләт мәнфәгатьләре өчен зур әһәмияткә ия булса, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты аларны туктату яисә туктатып тору турында карарлар кабул итә.

34 статья. **Татарстан Республикасы халыкара шартнамәсенең гамәлдә булуын туктату нәтиҗәләре**

Әгәр Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаса яки анда катнашучыларның башкалары белән бүтән төрле килешү булмаса, Татарстан Республикасы халыкара шартнамәсенең гамәлдә булуын туктату Татарстан Республикасын киләчәктә шартнамәне үтәү вазыйфаларыннан тулысынча азат итә һәм Татарстан Республикасының шартнамәне туктатканчыга кадәр аны үтәү нәтиҗәсендә килеп чыккан хокукларына, йөкләмәләренә яисә юридик халәтенә тәэсир итми.

35 статья. **Татарстан Республикасы халыкара шартнамәсенең гамәлдә булуын туктатып тору нәтиҗәләре**

1. Әгәр Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаса яки анда катнашучыларның башкалары белән бүтән төрле килешү булмаса, Татарстан Республикасы халыкара шартнамәсенең гамәлдә булуын туктатып тору Татарстан Республикасын шартнамәне туктатып торучыларга карата шартнамә туктатылган вакыт дәвамында шартнамәне үтәү йөкләмәләреннән азат итә һәм Татарстан Республикасының калган катнашучылар белән шартнамәдә билгеләнгән хокукый мөнәсәбәтләренә тәэсир итми.

2. Татарстан Республикасы халыкара шартнамәсенең гамәлдә булуын туктатып тору чорында Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары шартнамәнең яңадан гамәлгә керүенә комачаулык итүче гамәлләр кылмыйлар.

**36 статья. Халыкара шартнамәләрнең гамәлдә булуын туктатып тору һәм туктату турындагы хәбәрләр**

Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм туктату турындагы карарлар рәсми басылып чыгарга тиеш.

**37 статья. Гамәлгә кертү**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2282

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 663. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче пленар сессиясен чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче пленар сессиясен 1999 елның 15 сентябрендә Казан шәһәрендә чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф..Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 13 августы
№ 2311

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 664. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче пленар сессиясе каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче пленар сессиясе каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1.«Татарстан Республикасында дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

2.«Мактаулы ана» («Материнская слава») Татарстан Республикасы медален гамәлгә кую турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

3. «Латин графикасына нигезләнгән татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

4.«Гадәттән тыш хәлнең хокукый режимы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

5.«Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алдан билгеләнгән керемгә бердәй салым турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

6.«Коррупциягә каршы көрәш турында« Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 13 августы

№ 2312

# III
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 665. «Исәп-хисап ясауны җайга салу һәм хезмәт хакы түләүне тәэмин итү өчен финанс ресурсларын мобилизацияләү өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү турында

Барлык дәрәҗәдәге бюджетларга түләүләр буенча исәп-хисап ясауны җайга салу максатында һәм салым турындагы законнарның үзгәрүне уңаеннан карар бирәм:

1. Указның 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, Татарстан Республикасы Президентының «Исәп-хисап ясауны җайга салу һәм хезмәт хакы түләүне тәэмин итү өчен финанс ресурсларын мобилизацияләү өстәмә чаралар турында»гы 1996 елның 5 мартында чыгарылган 121 нче Указына (Татарстан Республикасы Президентының 1996 елның 27 июлендәге Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертергә:

«3. Салым түләүләрен күчерү вакытын һәм салымнарны, җыемнарны түләтү хакында салым органнары карарын үтәү срогын бозган өчен кредит оешмалары закон нигезендә җавапка тартылалар».

2. Указ кул куйган көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан, Кремль
1999 ел, 1 сентябрь
№ 697

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 666. Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итү турында

Казан тарихы буенча илебезнең һәм чит илләрнең галимнәре тарафыннан уздырылган киң масштаблы фәнни тикшеренүләр-

нең нәтиҗәләре һәм Казан шәһәренең барлыкка килүе хакында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенеә Россия Фәннәр академиясенең тарих бүлеге тарафыннан расланган бәяләмәсе нигезендә, Казан шәһәренең Татарстан Республикасы башкаласы, сәяси, фәнни-җитештерү һәм мәдәни үзәк буларак аерым әһәмияткә ия булуын билгеләп, **карар бирәм:**

1. Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын 2005 елның августында бәйрәм итәргә.

2. Халык депутатларының берләштерелгән Казан Советы президиумы һәм Казан шәһәр хакимиятенең Казан Шәһәре көнен ел саен 30 августта Татарстан Республикасы төзелгән көнне уздыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

3. Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерләнү һәм уздыру буенча Татарстан Республикасы Премьер-министры җитәкчелегендә Дәүләт комиссиясе (алга таба - Дәүләт комиссиясе) төзергә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына:

Дәүләт комиссиясенең составын һәм аның турында нигезләмәне расларга;

2000 елның 1 гыйнварына кадәр, төзелергә, реконструкцияләнергә тиешле объектларны ачыклап, чараларны финанслауның күләмен һәм чыганакларын билгеләп, республика һәм федераль бюджетлар, Казан шәһәр бюджеты средстволарын, шулай ук бюджеттан тыш фондларны, юридик һәм физик затларның ирекле кертемнәрен файдалануны күздә тотып, Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча чаралар программасын эшләргә һәм расларга;

Татарстан Республикасы башкаласы Казан шәһәренең статусы турында закон проекты эшләргә һәм аны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә;

Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын ЮНЕСКОның Истәлекле даталар календарена кертүне һәм әлеге халыкара оешманың юбилейны әзерләүдә һәм бәйрәм итүдә катнашуын үтенеп ЮНЕСКОга тәкъдим җибәрергә;

«Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итү турында» Россия Федерациясе Президенты Указының 4 пункты нигезендә Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын әзерләүдә һәм бәйрәм итүдә катнашу тәкъдиме белән Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнарына мөрәҗәгать итәргә.

5. Министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләренә, Татарстан Республикасы шәһәр һәм район хакимиятләре

башлыкларына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итүне әзерләүдә һәм уздыруда катнашырга.

6. Указ кул куйган көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан, Кремль
1999 ел, 1 сентябрь
№ УП-698

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 667. Тузган торак фондында яшәүче гражданнарга торак бирүнең кайбер үзенчәлекләре турында

Тузган торак фондын бетерү һәм тузган торак кварталларын реконструкцияләү программасын гамәлгә ашыру, тузган торакта яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту өчен өстәмә мөмкинлекләр тудыру максатында һәм Россиия Федерациясе Конституция Судының 1998 елның 2 февралендә чыгарылган 4-П карарын һәм гамәлдәге законнарын исәпкә алып, карар бирәм:

1. Тиешле тәртиптә даими рәвештә яшәргә яраксыз (тузган) дип танылганнан соң гражданнарны яшәү урыны буенча торак йортка (бинага) теркәү аларга үзеннән-үзе торак мәйданы алу хокукы бирми һәм шул ук вакытта гражданнар законнарда каралганча һәм чират тәртибендә яшәгән һәм эшләгән җирләрендә торак шартларын яхшыртырга хокуклы дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы район һәм шәһәр хакимиятләре башлыкларына тузган торак фондында яшәүче гражданнарга уңайлыклары булган торак биналардан торак биргәндә аның мәйданын гаилә составының балигъ булмаган балалар исәбенә үзгәртергә мөмкин булуын исәпкә алып, торак йортны (бинаны) даими яшәү өчен яраксыз (тузган) дип тану хакында карар кабул итү көненә гаиләнең составыннан һәм торак мәйданы бирүнең законда каралган нормасыннан чыгып билгеләргә.

3. Тузган торак фондында яшәүче гражданнарга хакын түләгәндә, билгеләнгән нормадан артыграк күләмдә уңайлыклары булган торак бирелергә мөмкин, ә шул рәвешле алынган акча средстволары уставта каралган бурычларны үтәү өчен Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт то-

рак фонды средстволарын тулыландыру өчен җибәрелә дип билгеләргә.

Бу очракта тузган торак фондында яшәүче яшь гаиләләргә, аларның теләге буенча, өстәмә торак мәйданының хакын түләү өчен, 10 елга кадәр түләп бетерү шарты белән, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фонды средстволары исәбеннән кайтарыла торган процентсыз ссуда алу хокукы бирелә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

1999 елның 1 октябренә кадәр гаиләнең составын, төзелеш өчен киткән чыгымнардан һәм торак базарында урнашкан реаль бәяләрдән чыгып торакның түләп алына торган өлешенең кыйммәтен билгеләү тәртибен исәпкә алып, шулай ук әлеге Указның 3 пункты нигезендә яшь гаиләләргә өстенлекләр бирүне күздә тотып, хакын түләү исәбенә билгеләнгән нормадан зуррак күләмдә уңайлыклары булган торак биналары бирү тәртибе турында нигезләмә эшләргә һәм расларга;

Татарстан Республикасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу һәм торак бирү Кагыйдәләренә әлеге Указ нигезендә тиешле үзгәрешләр кертергә.

5. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына ел саен чыгымнар сметасында өстәмә рәвештә бирелә торган торак мәйданына түләү өчен яшь гаиләләргә ссуда бирү максатында средстволар бүлүне карарга.

6. Татарстан Республикасы район һәм шәһәр хакимиятләре башлыкларына, һәр елның 31 декабренә кадәр, Татарстан Республикасы Президентына әлеге Указны гамәлгә ашыру, тузган торак фондын бетерү һәм тузган торак кварталларын реконструкцияләү программасының үтәлеше хакында мәгълүмат бирергә.

7. Указ басылып чыккан көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан, Кремль
1999 ел, 2 сентябрь
№ УП-705